ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

# ЭШ ПРОГРАММАЛАРЫН ТӨЗҮ БУЕНЧА МЕТОДИК ТӘКЪДИМНӘР

## (5 НЧЕ СЫЙНЫФ ӨЧЕН “ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ” ПРЕДМЕТЫ БУЕНЧА ЭШ ПРОГРАММАСЫ)

Казан
2015

**ББК 74.268.3Тат**
**Э98**

Проект җитәкчесе:
Р.Г. Хәмитов, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты ректоры, педагогика фәннәре кандидаты, доцент

Төзүче-авторлар:
Мөхәрләмова Г.Н., филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты
Гайфуллина Ф.Ә., филология фәннәре кандидаты, "Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте" укытучысы
Гыйләҗиева Л.Ф., Татарстан республикасы Арча районы 5 нче гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Зарипова М.Р., Татарстан республикасы Арча районы Яңа Кырлай урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Закирова А.Ф., Казан шәһәре Вахитов районы 96 нчы гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Мифтахутдинова А.З., Казан шәһәре Вахитов районы 96 нчы гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Салихҗанова И.Л., Казан шәһәре Совет районы аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 141 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Рахимова М.С., Казан шәһәре Совет районы аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 141 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

"Татар әдәбияты" предметының эш программасын төзү буенча методик тәкъдимнәр "Россия Федерациясендә Мәгариф турында"гы Федераль законы (№ 273-ФЗ, 29.12.2012), федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә һәм гомуми белем бирүнең төп белем бирү үрнәк программаларын исәпкә алып эшләнде.

Методик тәкъдимнәрдә бирелгән материал белем бирү оешмалары җитәкчеләре, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, методистлар өчен файдалы булачак.

**© ТРМҮИ, 2015**

# КЕРЕШ

Бүгенге мәктәп укучысы билгеле бер белем-күнекмәләргә генә ия булмыйча, үз уку эшчәнлеген планлаштыра белүче, гомере буе укуга сәләтле шәхес итеп тәрбияләнә. Әдәбият укыту белән бәйләп сөйләгәндә, бу аның киләчәктә мәктәпне тәмамлап чыккач та, матур әдәбият әсәрләрен аңлап, мөстәкыйль анализлый алучы китап укучысы булып формалашырга тиешлеген аңлата.

Мәктәптә әдәбият предметы әдәбиятны сүз сәнгате итеп кабул итүдә, укучының әдәби культурасын, эстетик зәвыгын, интеллектуаль һәм иҗади мөмкинлекләрен үстерүдә әһәмиятле роль уйный.

Билгеле булганча, һәр уку предметының эчтәлеге укытучы төзегән эш программасында чагылыш таба.

Эш программасы – ул укытучының белем бирү эшчәнлеген оештыру системасын характерлый торган норматив-идарә итү документы. Икенче төрле әйткәндә, программа укыту-методик документациянең җыелмасы булып тора (аңлатма язуы, уку предметының эчтәлеге, программаның бүлек һәм темаларны үз эченә алган календарь-тематик план, белем бирүнең планлаштырылган нәтиҗәләре, әлеге нәтиҗәләргә ирешүне бәяләү юллары һәм формалары). Гомуми белем бирүнең төрле баскычларында уку-укыту процессы әлеге программадан башка нәтиҗәле итеп оештырыла алмый.

Программаларны эшләү гомуми белем бирү оешмаларының уку-укыту, методик һәм норматив эшчәнлекнең аерылгысыз бер өлеше булып санала. Шул ук вакытта “Россия Федерациясендә Мәгариф турында”гы 273 нче номерлы Федераль законы уку предметы, курсы, дисциплинасының (модуленең) эш программасы дигән төшенчәне үз эченә алса да, биредә әлеге төр программага куела торган таләпләр билгеләнми, шул сәбәпле укытучы эш программасын төзегән вакытта төрле характердагы сораулар белән очрашырга мөмкин.

Әлеге методик тәкъдимнәрдә әдәбият предметы буенча эш программасының моделен төзү буенча киңәшләр бирелә, эш программасының структурасы, төп өлешләре, аны төзү юнәлешләре билгеләнә.

Эш программасының структурасын, өлешләрен төзүдә аерым уку предметының үрнәк программасының билгеле параметрлары хезмәт итә, чөнки үрнәк программа эш программасы төзүнең нигезләренең берсен тәшкил итә.

Эш программасын төзегәндә аның максатларын, бурычларын һәм функцияләрен дә истә тоту сорала.

Эш программасының төп максаты – белем бирүнең билгеле бер баскычында төп белем бирү программасының, уку планында каралган сәгатьләр санына туры килгән аерым ук предметы буенча үрнәк программаның эчтәлеген, дәрестән тыш эшләр планын, өстәмә белем бирү сәгатьләрен тормышка ашыру.

Эш программасының бурычларын түбәндәгеләр тәшкил итә:

- гомуми белем бирү оешмасының белем бирү эшчәнлегенең максатлары, бурычлары һәм укучыларның үзенчәлекләрен исәпкә алып аерым уку предметының эчтәлеген, күләмен, уку материалын өйрәнү тәртибен билгеләү;
- уку еллары һәм белем алу баскычлары эчтәлегенең дәвамчанлыгын тәэмин итү;
- төп гомуми белем бирү оешмасының билгеле бер шартларын, уку ихтыяҗларын һәм укучыларның үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып, педагогик эшчәнлекнең индивидуальлеген чагылдыру.

Эш программасының төп функцияләре:

- норматив (эш программасы тулы күләмдә эшләнергә тиеш);
- билгеле бер нәтиҗәгә исәп тоту (уку-укыту процессына кертүнең максатларын билгели);
- эчтәлекле (укучыларның үзләштерергә яки танышырга тиеш булган аерым уку предметы эчтәлеге элементларының составын билгели);
- аерым уку предметы буенча белем бирүнең эчтәлегендә дәвамчанлыкны булдыру;
- белем бирү эчтәлегендә интегратив юнәлеш принцибын тормышка ашыра;
- региональ предмет эчтәлегенең модульләрен үз эченә ала;
- системалы-эшчәнлекле юнәлешне тормышка ашыру өчен шартларны тәэмин итә;
- һәр укучының планлаштырылган нәтиҗәләренә ирешүен тәэмин итә;
- процессуаль (эчтәлек элементларын үзләштерүнең логик эзлеклелеген, уку-укытуны оештыру формаларын, методларын, чараларын һәм шартларын билгели);
- бәяләү (ФДББСны тормышка ашыру шартларында белем бирүнең дәрәҗәсенә туры килгән гомуми белем бирү программаларын үзләштерүдә предмет һәм метапредмет нәтиҗәләргә ирешү дәрәҗәсен ачыклый; ФДББСны тормышка ашыру шартларында эчтәлекне үзләштерү дәрәҗәләрен, контроль объектларын һәм укучыларның белем дәрәҗәсен бәяләү критерийларын билгели).

Аерым уку предметы буенча эш программасы түбәндәге өлешләрдән гыйбарәт:

1) аңлатма язуы (бередә аерым уку предметы спецификасын исәпкә алып, төп гомуми белем бирүнең гомуми максатлары конкретлаштырыла);
2) аерым уку предметының гомуми характеристикасы;
3) уку предметының гомуми уку планында тоткан урыны;
4) аерым уку предметын үзләштерүнең шәхескә кагылышлы, метапредмет һәм предмет нәтиҗәләре;
5) аерым уку предметының эчтәлеге;
6) укучыларның төп уку эшчәнлеге төрләрен билгеләгән тематик планлаштыру;
7) уку-укыту процессының укыту-методик тәэмин ителеше тасвирламасы;
8) аерым уку предметын өйрәнүнең планлаштырылган нәтиҗәләре.[1]

Аерым уку предметы буенча эш программасын килештерү һәм раслауның тәртибе гомуми белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә.

[1] "Төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларын раслау турында"гы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының боерыгы (№1897, 17.12.2010)

**ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ГОМУМИ ТӨПҺӘМ УРТА БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘПЛӘРЕ (V СЫЙНЫФ) ӨЧЕН ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ЭШ ПРОГРАММАСЫ**

(Әдәбият. 5 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы /Ф.Ә. Ганиева, Л.Г. Сабирова / – Казан: Татар.кит.нәшр., 2014. – 175 б. дәреслеге буенча)

Төзүче-авторлары: Гайфуллина Ф.Ә., филология фәннәре кандидаты, "Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте" укытучысы

Гыйләҗиева Л.Ф., Татарстан республикасы Арча районы 5 нче гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Зарипова М.Р., Татарстан республикасы Арча районы Яңа Кырлай урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

## Аңлатма язуы

5 нче сыйныфлар өчен татар әдәбиятыннан эш программасы Россия Федерациясендәге һәм Татарстан Республикасындагы мәгарифкә кагылышлы хокукый-норматив актларга һәм федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелде:

1. Россия Федерациясенең "Мәгариф турында"гы Законы (Федеральный закон от 29.12.2012 273-ФЗ "Об образовании в Российской Федерации")
2. Татарстан Республикасының "Мәгариф турында"гы Законы (Закон Республики Татарстан "Об образовании" № 68-ЗРТ от 22 июля 2013 года, статья 8)
3. Россия Федерациясенең "Россия Федерациясе халыктелләре турында"гы 126-ФЗ нчы номерлы Законы (24.07.1998)
4. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы приказы, 30 нчы август, 2013 нче ел №115 ("Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – начального общего, основного общего и среднего общего образования")
5. "Татарстан Республикасының халык телләре турында" Законы (Закон Республики Татарстан от 08.07.1992 № 1560-XII (ред. от 03.03.2012г.) "О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан")
6. "Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" Татарстан Республикасы Законы, 2004нче ел, 1нче июль
7. "2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы", 2013 нче ел, 25 нче октябрь, 794 нче карар
8. Төп гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандарты (Россия Мәгариф һәм Фән министрлыгында 2010 нчы елның 17 нче декабрь боерыгы 1897 нче номер белән расланган, РФ Юстиция Министрлыгында 19644 нче регистрацион номеры белән 2011нче елның 1 нче феврfalendә теркәлгән)
9. Татарстан Республикасында 2012-2020 нче елларда фән һәм мәгариф үсеше турында "Дәүләт программасы"
10. 2010-2015 нче елларда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү стратегиясе "Киләчәк" программасы

5 нче сыйныф өчен "Әдәбият" курсының эш программасы Федераль дәүләт белем бирү стандартларының таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм

фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән “Татар телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләренең 1-11 нче сыйныфлары өчен татар әдәбиятын укыту программалары” (Төзүче-авторлары: Ф.Г.Галимуллин, Ф.Ә.Ганиева, Д.Ш.Сибгатуллина). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011), 5 нче сыйныф өчен Ф.Ә. Ганиева, Л.Г. Сабирова эшләгән (Казан: Татар. кит. нәшр., 2014) Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслеккә нигезләнеп төзелде.

Дәреслек: Әдәбият. 5 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы /Ф.Ә. Ганиева, Л.Г. Сабирова / - Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 175б.

**Татар балалары өчен әдәбият укытуның төп максаты**

Балаларда туган телгә, әдәбиятка карата кызыксыну уяту, татар әдәбиятының бай тарихы, халык авыз иҗаты, талантлы әдипләре, аларның күркәм әсәрләре белән таныштыру. Әсәрләрне аңларга, эзлекле фикер йөртергә, әсәрләрне матурлык ноктасыннан бәяләп кабул итәргә өйрәтү.

**Бурычлары:**

- иҗат, әдәбият үсеше, аның тарихи төшенчәләрен аңлап фикер йөртергә өйрәтү;
- әдәбиятның формалашуында һәм үсүендә зур роль уйнаган күренеш – халык авыз иҗаты, аның матур әдәбият белән уртак һәм аермалы якларын күрсәтү;
- матур әдәбиятны милли һәм дөньякүләм культураның бер күренеше итеп карау, аның рухи кыйммәтләрне, традицияләрне саклаучы, тапшыручы икәнен аңлату;
- әдәби әсәрне өлешчә анализлау күнекмәләре булдыру,әдәбият теориясе буенча билгеле бер күләмдә теоретик белемнәр бирү;
- әдәби әсәрдә тасвирланган тормыш вакыйгаларыннан үрнәк һәм гыйбрәт алырга, дөрес, гадел максатлар куярга өйрәтү;
- әдәбиятның матурлыгын, хис кичерешләр байлыгынкүрсәтеп, балаларның рухи дөньясын баету;
- укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү;
- үз мәнфәгате һәм җәмгыять мәнфәгате өчен иҗади мөмкинлеген тормышка ашырырга сәләтле шәхес тәрбияләү;
- сөйләм культурасы булдыру.

**Белем дәрәҗәсенә таләпләр:**

- әдәби әсәрне иҗтимагый һәм мәдәни тормыш күренешләре белән бәйлелектә карау;
- халык авыз иҗаты һәм матур әдәбиятның уртак сыйфатларын, үзенчәлекләрен белү;
- эчтәлек һәм форма берлеген аңлау;
- әсәрнең темасын, проблемасын, идеясен билгеләү;
- әдәби образларны (кеше, табигать һ.б.) тану;
- әдәби детальләрне таба белү;
- сурәтләү чараларын табу;
- әдәби төрләр, жанрларны таный һәм аера белү.

**Күнекмәләргә таләпләр:**

- әдәби әсәрнең эчтәлеген белү;
- әсәрдәге каршылыкны, төп фикерне табу;

- әсәр геройларына характеристика бирү;
- әдәби әсәр буенча план төзү;
- әсәргә карата үз фикереңне әйтә белү;
- бәйләнешле сөйләм булдыру;
- өйрәнелгән әсәрләр буенча яки бирелгән тема буенча сочинение яза белү;
- шигырьләрне сәнгатьле итеп уку;
- тәкъдим ителгән яки укучы үзе сайлаган әсәрләрне (шигырь, проза) яттан сөйләү.

**Уку фәненең уку планында тоткан урыны**

Мәктәптә әдәбият предметы – кирәкле, әһәмиятле предметларның берсе. Ул укучыларны тормышны үзенчәлекле итеп танып белергә өйрәтә, хисси-эмоциональ дөньясын баета, эстетик зәвык тәрбияли, сөйләмен үстерә, гомумән, шәхес итеп тәрбияләүдә зур роль уйный.

Татар әдәбияты предметы төп мәктәптә 5-9 сыйныфларда өйрәнелә. 5-8 сыйныфларда әдәбият укытуга 35 атна исәбеннән атнага 2 сәгать) 70 (35) сәгать, 9 нчы сыйныфта 68 сәгать каралган.

**Укытуның көтелгән нәтиҗәләре**

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

- туган илгә мәхәббәт, ватанпәрвәрлек хисләре, туган телгә сакчыл караш тәрбияләү;
- милли үзаң формалаштыру;
- укуга карата теләк-омтылыш, җаваплы караш булдыру;
- әйләнә-тирә табигатькә дөрес караш булдыру;
- кешеләр белән аралаша белү культурасы тәрбияләү;
- гаделлек, дөреслек, яхшылык, мәрхәмәтлелек һәм аларның киресе булган сыйфатларны тану, бәяләү;
- алган белем һәм осталыкны тормышта максатчан кулланырга өйрәнү.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

**Танып-белү гамәлләре:**

- әдәби әсәрне дөрес аңлап уку һәм анализлау;
- дөрес нәтиҗәләр чыгару, гомумиләштерү;
- сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булдыру;
- үз фикереңне исбатлый һәм яклый алырга күнектерү;
- әсәр хакында дөрес фикер йөртә алу.

**Коммуникатив гамәлләр:**

- иптәшеңне тыңлый, ишетә белү, ишеткәнен үз фикере белән чагыштыру;
- нәтиҗәгә килгәнче, төрле карашларны өйрәнү һәм дөрес юлны сайлау;
- үз фикереңне телдән һәм язма формада башкаларга җиткерә белү;
- килеп чыккан проблемаларны уртага салып хәл итү;
- төркемнәргә берләшү, бер фикергә килә белү;
- өлкәннәр һәм яшьтәшләрең белән продуктив уртак гамәл оештыру;
- текст буенча сораулар бирә белү.

**Регулятив гамәлләр:**

- дәреснең темасын, проблемасын, максатын мөстәкыйль таба белү;
- укыту проблемасын чишү;

- план буенча эшли белү;
- үз фикерләреңне мөстәкыйль дәлилләү;
- үзанализ һәм үзбәя булдыру.

**Предмет нәтиҗәләр:**

- халык авыз иҗаты әсәрләрен үзләштерү, аның матур әдәбият белән уртак сыйфатларын һәм үзенчәлекләрен аера белү;
- әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлау, төп фикерне таба белү;
- әсәрләрне иҗтимагый һәм мәдәни тормыш күренешләре белән бәйлелектә аңлау;
- язучыларның тормыш һәм иҗат юлларының мөһим фактларын истә калдыру;
- әдәбият теориясе буенча билгеле бер күләмдә теоритек белемгә ия булу;
- әсәрдә автор карашларын ачыклау һәм әсәргә карата үз фикереңне әйтә белү;
- әдәби әсәрне эчтәлек һәм форма берлегендә аңлау.

**Татар мәктәбенең 5 нче сыйныфында укучы татар балаларына әдәбияттан тәкъдим ителә торган әсәрләр минимумы**

«Ак бүре» әкияте (кыскартып)
«Шәһәр ни өчен Казан дип аталган» риваяте
«Зөһрә кыз» легендасы
«Иске кара урман» җыры.
«Сак–Сок» бәете
Г.Тукайның «Шүрәле» әкияте
Г.Тукайның «Пар ат», «Туган җиремә» шигырьләре
Ф.Әмирханның «Ай өстендә Зөһрә кыз» хикәяте
М.Гафуриның «Сарыкны кем ашаган?» мәсәле
Ш.Галиевнең «Һәркем әйтә дөресен» шигыре
Ф.Яруллинның «Сез иң гүзәл кеше икәнсез» шигыре

**Курсның эчтәлеге**

Халыкның милли, рухи мәдәният хәзинәсе буларак халык иҗаты. Аның сәнгать төрләре формалашуга йогынтысы. Халык иҗатының бер төре буларак халык авыз иҗаты. Аның әсәрләрендә гомумкешелек хыяллары, идеалларының чагылуы. Халык авыз иҗатының матур әдәбият белән бәйләнешләре: уртаклыгы һәм үзенчәлекле аермалары. Халык авыз иҗатының төп жанрлары, жанр сыйфатлары**.**

Әкиятләр: жанр төрләре, үзенчәлекле сыйфатлары. “Ак бүре” әкияте ( кыскартып). “Үги кыз”, “Аю белән төлке” әкиятләре.

Җырлар: татар халык җырларына хас үзенчәлекләр. Көй һәм сүзләр тәңгәллеге. “Моң” төшенчәсе. Җырларны төркемләү. “Иске кара урман”, ”Гөлҗамал”,”Туган ил”,”Яшә, Республикам!”,”Ай былбылым”; кыска җырлар - дүртюллыклар; тарихи җырлар: “Болгар иленең кызлары”,”Пугач явы”.

Кыска жанрлар: мәкальләр һәм әйтемнәр. табышмаклар, мәзәкләр. “Хуҗа Насретдин мәзәкләре”. Бәетләр. “Сак-сок” бәете.

Риваятьләр, легендалар: аларга хас үзенчәлекләр; жанр сыйфатлары.“Янмый торган кыз”,”Иске Казан каласының корылуы”,”Шәһәр нигә Казан дип аталган”,”Әллүки”,”Зөһрә кыз”,”Кеше гомере ничек корылган”.

Халык авыз иҗатында образлар; әсәрләрдә дөнья сурәте; табигать һәм кеше, яшәеш һәм кеше турында күзаллаулар. Халык авыз иҗаты поэтикасы, язма әдәбият үсешенә, әдәби телгә зур йогынтысы.

Әдәби әкиятләр: халык әкиятләре белән уртаклык; сәнгатьлелек сыйфатлары, әдәби әсәр буларак алым һәм сурәтләү чаралары.

Г.Тукайның “Шүрәле” әкияте.

Җ.Тәрҗемановның “Тукран малае Шуктуган” әкияте.

Әхмәт Фәйзинең “Аучы мәргән белән Болан кыз” әкияте.

Рабит Батулланың “Курай уйный бер малай” әкияте.

Фәнис Яруллинның “Зәңгәр күлдә ай коена”,”Кояштагы тап”әкиятләре.

Хикәя: жанр сыйфатлары; әсәрнең катламнары – вакыйгалар, күренешләр, хис-кичерешләр; кеше образлары - төп герой, ярдәмче геройлар, җыелма образлар; хикәяләүче образы, автор позициясе.Фатих Әмирханның “Ай өстендә Зөһрә кыз”,”Нәҗип” хикәяләре.

Мәсәл. Тереклек, җансыз предмет образлары ярдәмендә, читләтеп, кеше сыйфатларын һәм тормышын тасвирлау. Хикәяләп яки тезмә рәвештә язылуы; фикер-идеяләрнең аллегория ярдәмендә белдерелүе.

Мәҗит Гафуриның “Сарыкны кем ашаган?” мәсәле.

Габдулла Тукайның “Ике сабан” мәсәле.

Сәнгатьтөре буларак матур әдәбият; чәчмә һәм тезмә әсәр; аларның сәнгатьчә сурәтләү алымнары, чаралары.

Шигърият.

Габдулла Тукайның “Пар ат”,”Туган җиремә”,”Туган авыл” шигырьләре.

Шәүкәт Галиев. Балалар әдәбиятындагы урыны; геройлары, образлар дөньясы. “Һәркем әйтә дөресен”,”Тереклек суы”,”Курыкма, тимим!”, “Тарихтан сабак”,”Өйгә бирелгән эш”,”Онытылган, өйдә калган” шигырьләре. ( 4 сәг.)

**Бәйләнешле сөйләм үстерү - 8 сәгать**

**Ятлау һәм сәнгатьле итеп сөйләү өчен әсәрләр:**

1. Г.Тукайның “Шүрәле” әсәре, 1 – бүлек.
2. Г.Тукайның үзегез яраткан шигыре.
3. Ф.Яруллинның “Сез иң гүзәл кеше икәнсез” шигыре.
4. Укытучы яки укучылар сайлап алып, Ш.Галиевнең бер шигыре.

**Инша язу өчен үрнәк темалар:**

1. Әкият геройларының көрәш максатлары һәм җиңүгә китергән сәбәпләр, шартлар (өйрәнгән әсәрләр мисалында).
2.“Сак-сок”бәетендә тасвирланган халык акылы һәм синең үз нәтиҗәләрең.
3. Әдәби әкиятләрдә табигать һәм кеше образларына салынган фикерләр, нәтиҗәләр (өйрәнгән әсәрләр мисалында).
4.”Минем туган җирем” (Г.Тукай һәм башка язучыларның әсәрләрен файдаланып, һәркем үз образын иҗат итә).

**Дәрестән тыш уку өчен - 4 сәгать**

1. “Гөлчәчәк” татар халык әкияте.
2. Ләбиб Лерон. Шаян хикәяләр, шигырьләр, әкиятләр.
3.Фаил Шәфигуллинның “Акмөгез”хикәясе.
4. Вакытлы матбугат басмалары.

## Тематик планлаштыру

| № | Төп темалар | Уку-укыту эшчәнлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|---|
| 1. | Кереш. Халык авыз иҗаты | Халык авыз иҗаты турында белемнәрне тирәнәйтү, системалаштыру, халык авыз иҗаты һәм матур әдәбиятның уртак һәм аермалы якларын күрсәтү | 1 |
| 2. | Әкият. “Ак бүре” әкияте | Әкият турында булган белемнәрне тирәнәйтү. “Акбүре” әкиятен уку, анализлау. Әкият геройларын өйрәнү, аларга бәя бирү | 4 |
| 3. | “Үги кыз”, “Аю белән төлке” әкиятләре | Текстны уку, сорауларга җавап бирү, эчтәлеген ачыклау, идеясен билгеләү, әкиятләрне төрләргә аеру, аларның үзенчәлекләрен билгеләү | 4 |
| 4. | Халык авыз иҗатында җыр жанры. “Иске кара урман”, “Гөлҗамал”, “Туган ил”, “Яшә, Республикам!”, “Ай былбылым”; кыска җырлар - дүртъюллыклар; тарихи җырлар: “Болгар иленең кызлары”, “Пугач явы” | Җыр жанры турында мәгълүмат алу, җырларны тыңлау, идея эчтәлеген ачыклау Көйләр яңгырашындагы уртаклык һәм аермалыкларны табу. Текстлардагы төп һәм кушымта өлешләрне аерып күрсәтү Озын һәм кыска җырларны, татар халык җырларын башка халык җырлары белән чагыштыру. Тарихи җырларда сурәтләнгән геройлар турында мәгълүмат туплау | 4 |
| 5. | Халык авыз иҗатында кыска жанрлар: мәкальләр һәм әйтемнәр, табышмаклар, мәзәкләр. “Хуҗа Насретдин мәзәкләре” | Мәкальләрнең килеп чыгышы, төзелеше турында мәгълүмат алу. Табышмакларның төзелешен өйрәнү. Мәзәкләрне уку, эчтәлеген ачыклау, мәзәкләрдә халыкның тапкырлыгы, шат күңеле, оста булуын күрсәтү | 5 |
| 6. | Бәетләр. “Сак-сок” бәете | Үзләре укыган, ишеткән бәетләрне сөйләү, фикер алышу. Бәетне уку һәм анализлау, текстка якын килеп эчтәлеген сөйләү | 2 |
| 7. | Риваятьләр, легендалар. “Янмый торган кыз”,”Иске Казан каласының корылуы”,”Шәһәр нигә Казан дип аталган”,”Әллүки”,”Зөһрә кыз”,”Кеше гомере ничек корылган” | Риваять һәм легендаларны уку, анализлау. Башка халык авыз иҗаты әсәрләре белән чагыштыру, сурәтләү чараларын табу | 4 |
| 8. | Практик дәрес.Халык авыз иҗатында образлар | “Ак бүре”, “Үги кыз” әкиятләрендәге образларны тикшерү, әңгәмәдә катнашу. “Образ (сурәт)”, “поэтика” төшенчәләрен өйрәнү | 2 |
| 9. | Әдәби әкиятләр. Г.Тукай “Шүрәле” | Әдәби әкиятләргә мисаллар китерү. Эчтәлекләрен искә төшереп сөйләү. Әкият-уку һәм анализлау. Поэмада вакыйгаларны, төп геройларны күрсәтү | 2 |
| 10. | Ж.Тәрҗемановның “Тукран малае Шуктуган” әкияте | Текстны уку, сорауларга җавап эзләү, әкиятнең эчтәлеген аңлау, төп фикерне билгеләү | 3 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11. | Әхмәт Фәйзинең “Аучы мәргән белән Болан кыз” әкияте | Әкияте уку, төп фикерне аеру, әкият геройларына бәя бирү, сөйләү, әңгәмәдә катнашу | 3 |
| 12. | Рабит Батулланың “Курай уйный бер малай” әкияте | Әсәр буенча әңгәмә кору, үз мөнәсәбәтләрен белдереп, әкиятнең эчтәлеген сөйләү | 3 |
| 13. | Фәнис Яруллинның “Зәңгәр күлдә ай коена”, “Кояштагы тап” әкиятләре | Укытучы сөйләвен тыңлау, язучы биографиясе буенча хронологик таблица төзү. Әкиятләрне уку, әкият буенча сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү, геройга бәя бирү | 3 |
| 14. | Хикәя. Фатих Әмирханның “Ай өстендә Зөһрә кыз”, “Нәҗип” хикәяләре | Хикәяләрне уку, анализлау, хис-кичерешләргә, геройларга бәя бирү, сурәтләү чараларын табу, хикәянең үзенчәлекләрен билгеләп, төшенчә итеп чыгару | 5 |
| 15. | Мәсәл. Мәҗит Гафуриның “Сарыкны кем ашаган?” мәсәле | Таныш булган мәсәлләрне искә төшерү, эчтәлекләрен сөйләп карау. Мәсәлне уку, анализлау, идеяне чыгару | 2 |
| 16. | Габдулла Тукайның “Ике сабан” мәсәле | Әсәрне уку, эчтәлеген аңлау, фикер алышу, идеясен билгеләү | 1 |
| 17. | Практик дәрес. Сәнгать төре буларак матур әдәбият; чәчмә һәм тезмә әсәр | Хикәядәге сурәтләү чараларын табу, аларның әһәмиятен билгеләү. Шигырь тезмәләренең озынлыгын билгеләү; ритм, рифмаларны күзәтү, нәтиҗәләр ясау | 2 |
| 18. | Габдулла Тукайның “Пар ат”, “Туган җиремә”, “Туган авыл” шигырьләре | Шигырьләрне уку, анализлау, хис-сәбәп бәйләнешен ачыклау, сурәтләү чараларын табу | 3 |
| 19. | Шәүкәт Галиев. Балалар әдәбиятындагы урыны; геройлары, образлар дөньясы. “Һәркем әйтә дөресен”, ”Тереклек суы”, ”Курыкма, тимим!”, “Тарихтан сабак”, ”Өйгә бирелгән эш”, ”Онытылган, өйдә калган” шигырьләре | Шигырьләрне сәнгатьле итеп уку, төп фикерне аерып чыгару, фикер алышу | 3 |
| 20. | Ф.Яруллин “Сез иң гүзәл кеше икәнсез” | Шигырьне уку, анализлау, фикер алышу | 1 |
| 21. | Бәйләнешле сөйләм үстерү | Тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, иҗади эш башкару. Сочинение язу өчен план төзү, план буенча сочинениене мөстәкыйль язу | 8 |
| 22. | Дәрестән тыш уку | Дәрестән тыш әдәби әсәрләр уку, аларның эчтәлеген сөйли алу | 4 |
| 23. | Йомгаклау дәресе | Уку елы буена үткәннәрне кабатлау, әңгәмәдә катнашу, нәтиҗә ясау | 1 |
| | Барлыгы: | | 70 |

**Укытуны матди-техник яктан һәм мәгълумати яктан тәэмин итү**

Укытуны матди-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү нигезенә түбәндәгеләр кирә:

- белем һәм тәрбия бирү өчен барлык шартлар да тудырылган, санитария һәм янгыннан саклану нормаларына туры килгән уку бинасы булу;
- әдәбиятны өйрәнү өчен җитәрлек күләмдә дәреслекләр һәм өстәмә методик ярдәмлекләр белән тәэмин ителгән китапханә;
- электрон китапханә, башка электрон ресурслар, татарча сайтлардан куллану мөмкинлеге булган компьютер классы;
- лингафон кабинеты;
- электрон һәм басма күрсәтмә әсбаплар, дәреслекләр;
- мультимедиа укыту программалары, компьютер программалары;
- укучыларының белемнәрен тикшерү программалары;
- төрле типтагы сүзлекләр, энциклопедияләр;
- белешмә материаллар;
- балалар өчен чыгарылган газета һәм журналлар;
- интерактив тикшерү программалары;
- татар сайтлары (belem.ru; tatarile.org.com ).

**Әдәбият исемлеге**


1. Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Әхмәдуллин. – Казан:Татар.кит.нәшр., 1990
2. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: “Мәгариф”, 2007.
3. Әдипләребез: библиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2009.
4. Әдипләребез: библиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том/ төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2009
5. Дастаннар. – Казан: Мәгариф, 2001.
6. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау. – Казан: Мәгариф, 2005.
7. Заһидуллина Д.Ф Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2000.
8. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов А.М. Татар әдәбияты: Теория. Тарих.– Казан: Мәгариф, 2006.
9. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре. 3 томда. – Казан:Татар.кит.нәшр., 2010.
10. Исламов Ф.Ф. Әдәби викториналар – әдәбиятка, сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләүдә кыйммәтле чара. – Казан, 2005.
11. Йосыпова Н.М. XXгасыр татар шигъриятендә символлар. – Казан: Мәгариф, 2006.
12. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002.
13. Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1983 – 2001.
14. Татар әдәбияты. Теория.Тарих./Д.Заһидуллина, Ә.Закирҗанов, Т.Гыйлаҗев, Н.Йосыпова. – Казан: Мәгариф, 2006.
15. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1977, 1979, 1981.
16. Тарих мең дә сигез йөз дә: Бәетләр, мөнәҗәтләр. – Казан: Мәгариф, 2000.

**Күрсәтмә материаллар**

Электрон ресурслар: “Бала” китапханәсе, “Татар мультфильмнары”, мультимедиа укыту программалары; электрон китапханә; татар сайтлары (belem.ru, tatarile.org.com); аудио һәм видео әсбаплар:

- Габдулла Тукай. Интерактив мультимедиа уку-укыту әсбабы.
- Габдулла Тукай. Энциклопедия. Дисклар коллекциясе.
- «Габдулла Тукай», «Вамин» Татарстанның мәдәни традицияләрен саклау һәм үстерү фонды, DVD и 1 CD дан торган җыентык, 2009.
- Классик әдәбиятыбыз үрнәкләре. Татар әдәбиятыдәресләренә фонохрестоматия (5-11 сыйныфлар). CD 4 форматлы. Төзүчесе: Газимҗанова Р.Г.
- Шигърият бакчасында. Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия (5-11 сыйныфлар) CD 1, CD 2, CD 3 форматлы. Төзүчесе: Газимҗанова Р.Г.
- Фәнис Яруллин. Тормышы һәм иҗатына багышланган методик әсбап. Мультемедиа басма.
- Язучыларыбыз чыгышлары һәм алар турында истәлекләр. Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия (5-11 сыйныфлар). CD5 форматлы. Төзүчесе: Газимҗанова Р.Г.
- Язучылар, композиторлар һәм рәссамнар чыгышлары, алар турында истәлекләр. Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия (5-11 сыйныфлар). CD 6 форматлы. Төзүчесе: Газимҗанова Р.Г.

# Кушымта
## Календарь-тематик план[1]

| № | Дәрес темасы | Дәрес тибы | Төп эчтәлек | Планлаштырылган нәтиҗәләр | | | Укучылар эшчәнлеге төрләре | Контрольнең төрләре һәм формалары | Үткәрү вакыты план / факт |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | шәхескә кагылышлы | метапредмет | предмет | | | |
| 1 | Кереш. Халык авыз иҗаты | Катнаш дәрес | Халык авыз иҗаты турында белемнәрне тирәнәйтү, системалаштыру, халык авыз иҗаты һәм матур әдәбиятның уртак һәм аермалы якларын күрсәтү | Сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итү | Фольклор жанрларны, аларга хас үзенчәлекләрне аера белү | Халык авыз иҗаты аша халкыбыз тарихы турында мәгълүматлы булу | Халык авыз иҗаты турында булган белемнәрне искә төшерү. Үзләре белгән халык авыз иҗаты әсәрләрен сөйләп күрсәтү | | |
| 2-3 | Әкиятләр.“Ак бүре” әкияте. I-II бүлек. | Катнаш дәрес | Әкият турында булган белемнәрне тирәнәйтү. “Акбүре” әкиятенең I бүлеген уку, анализлау | Үзеңдә милли гореф-гадәтләр турында караш булдыру | Әкият жанрының асылына төшенү, үз фикерен төгәл һәм тулы итеп җиткерә белү | “Акбүре” әкиятенең I бүлеген уку, анализлау | Әкият буенча план төзү, план буенча әкиятнең эчтәлеген сөйләү. Әсәрнең темасын, проблемасын, идеясен билгеләү | | |
| 4-5 | “Акбүре” әкиятендә образлар системасы | Катнаш дәрес | Әкият геройларын өйрәнү, аларга бәя бирү | Матурлыкны күрә белергә өйрәнү | Төп геройга бәя бирү аша авторның фәлсәфи, эстетик, әхлакый карашларын ачыклау | “Акбүре” әкиятенең I бүлеген уку, анализлау. Әдәби образны тикшерү-бәяләү | Әкият геройларына характеристика бирү, үз фикерләрен әсәрдән китерелгән мисаллар белән дәлилләү | | |

[1] Укыту-методик тәэмин итү буларак укытучы календарь-тематик планны бирә ала

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | “Аю белән төлке” әкияте | Әдәби әсәр өйрәнү | “Аю белән төлке” әкиятен уку, анализлау | Татар халык иҗатына хөрмәт хисе, аларны өйрәнү теләге булдыру | Логик фикерләүне үстерү, төп фикерне билгели, аны үз сүзләре белән әйтеп бирү алу | “Аю белән төлке” әкиятен уку, анализлау. Әкиятнең идея эчтәлеген белү. | Текстны уку, сорауларга җавап бирү, эчтәлеген ачыклау, идеясен билгеләү | | |
| 7-8 | “Үги кыз” әкияте | Әдәби әсәр өйрәнү | “Үги кыз” әкиятен өйрәнү | Үзеңдә мәрхәмәтлелек сыйфатлары булдыру | Әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белүгә ирешү, әкият эчтәлеген аңлау, төп фикерне таба белү | “Үги кыз” әкиятен уку, анализлау. | Текстны уку, әсәр буенча план төзү, фикер алышу | | |
| 9 | Б.С.Ү.Әкият язу | Бәйләнешле сөйләм үстерү | Әкият язу | Иҗади сәләтеңне үстерү | Үз уеңны, фикереңне төгәл әйтә белү | Әкият язу. Язма сөйләм үстерү | Тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, иҗади эш башкару | Язма эш | |
| 10 | Д.Т.У. “Гөлчәчәк” әкияте | Белемнәрне тирәнәйтү, системалаштыру | Әкиятне уку, анализлау | Аралашу культурасы булдыру, әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү | Әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, ишетә белү, ишеткәнеңне үз фикерең белән чагыштыру, әдәби әсәрне аңлап укырлык, мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру | “Гөлчәчәк” әкиятен уку | Дәрестән тыш әдәби әсәрләр уку, аларның эчтәлеген сөйли алу | | |
| 11 | Әкият төрләре | Яңа материалны аңлату | Әкият төрләре турында мәгълүмат бирү | Эстетик зәвык булдыру | Тема буенча сораулар бирә белү, үз фикерен дәлилле җиткерү, билгеле бер күрсәтмә нигезендә эшли белү | Әкият төрләрен аера белү | Үзләренә тиеш булган әкиятләрне төрләргә аеру, аларның үзенчәлекләрен билгеләү | | |
| 12 | Б.С.Ү. Сочинение язу. Әкият геройларының көрәш | Белемнәрне ныгыту, системалаштыру | Укыган әкиятләрең, аларга булган мөнәсәбәтең, уйхыялларыңны белдереп язу | Сөйләм телен, язу культурасын һәм иҗади фикерләвен үстерү | Әдәбиятка үз мөнәсәбәтеңне белдерү, үз сүзеңне әйтә белү. Материалны аерып алу, тиешле тел ка- | Әкият геройларының көрәш максатлары һәм җиңүгә китергән сәбәпләр, шартлар буенча | Сочинение язу өчен план төзү, план буенча мөстәкыйль язу | Сочинениение | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | максатлары һәм җиңүгә китергән сәбәпләр, шартлар (өйрәнгән әсәрләр мисалында) | | | | лыбы табу, уку, төзәтү, төрле ярдәмлекләрдән, сүзлекләрдән файдалана белү | сочинение язу | | | |
| 13 | Җыр | Лекция-әңгәмә | Халык авыз иҗатында җыр жанры. Татар халык җырларына хас үзенчәлекләр | Матурлыкны күрә белү, халык тормышында җырның әһәмиятен аңлау | Милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңелдән уздырып кабул итәргә өйрәнү, әңгәмә кора белү | Җырның килеп чыгышы, табигате, төркемнәре, үзенчәлекләре, әһәмияте турында мәгълүматлы булу | Татар халык җырларын тыңлау, тыңланган әсәрләргә карата фикерләрен белдерү, әңгәмәдә катнашу | | |
| 14 | Халык җырларының килеп чыгышы | Лекция-әңгәмә | “Кара урман”, “Гөлҗамал” җырларын тыңлау, анализлау | Эстетик зәвык булдыру, җырларда халыкның туган иленә, җиренә, батырларына булган мәхәббәтен чагылдыруны аңлау | Тексттан кирәкле мәгълүматны аерып чыгара белү, башкалар фикерен тыңлый, бәяли белү | Җырларның борын-борыннан килгән тормыш юлдашы булуын, кеше күңеленең төрле халәтендә тууын, халыкның тормыш-көнкүрешен, аның уй-кичерешләрен чагылдыруын аңлау | “Кара урман”, “Гөлҗамал” җырларын тыңлау, идея эчтәлеген ачыклау. Көйләр яңгырашындагы уртаклык һәм аермалыкларны табу. Текстлардагы төп һәм кушымта өлешләрне аерып күрсәтү | | |
| 15 | Җырларның табигате | Лекция-әңгәмә | “Туган ил” (Н. Исәнбәт сүзләре), “Яшә, республикам!”, “Ай былбылым” җырларын тыңлау, анализлау | Туган илгә хөрмәт хисе тәрбияләүне аңлау | Сәнгатьнең ике мөстәкыйль төрен – музыка һәм поэзия үзендә берләштергән иҗат булуын аңлау, текстларны чагыштыра белү, уртак якларны билгеләү | Җырларның башкару өчен иҗат ителүен, көй белән текстның бергә кулланылуының тышкы күренеш кенә булмыйча, җырның эчке табигате белән генә аңлатыла торган идея-эстетик бер- | “Туган ил” (Н. Исәнбәт сүзләре), “Яшә, республикам!”, “Ай былбылым” җырларын тыңлау, идея эчтәлекләрен ачу. Аларны чагыштыру | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | лек булуына төшенү | | | |
| 16 | Җырларны төркемләү | Яңа материалны аңлату | Җырларны төркемнәргә бүлү. Озын һәм кыска җырлар. Тарихи җырлар, тормыш-көнкүреш җырлары, лирик җырлар | Тарихи җырларның патриотик эчтәлекле һәм героик пафос белән сугарылган кыйммәтле мирас булуына төшенү | Җырларны аерым билгеләре буенча чагыштыру, төркемнәргә аера белү, билгеле бер критерийлар буенча классификацияли белү. Фикерләрне тулы һәм төгәл итеп җиткерә алу, дәлилләү | Җырларны төркемнәргә аера белү. Сәнгать турында белемнәрне тирәнәйтү | Озын һәм кыска җырларны, татар халык җырларын башка халык җырлары белән чагыштыру. Тарихи җырларда сурәтләнгән геройлар турында мәгълүмат туплау | | |
| 17 | Халык авыз иҗатында кыска жанрлар. Мәкальләр | Белемнәрне тирәнәйтү, системалаштыру | Мәкальләрнең килеп чыгышы, идея-тематикасы, аларның әһәмияте | Мәкальләрнең кеше тормышындагы әһәмиятен аңлау | Мәкальләрне сөйләмдә урынлы куллана белү. Сөйләм телен баету | Мәкальләрнең төзелешен, поэтикасын өйрәнү | Мәкальләрнең килеп чыгышы, төзелеше турында мәгълүмат алу, сорауларга җавап бирү | | |
| 18 | Табышмаклар | Белемнәрне тирәнәйтү, системалаштыру | Табышмак жанрының тууы, үсүе, халыкның рухи тормышында әһәмиятле роль уйнавы | абышмакның кеше тормышында әһәмиятле роль уйнавын аңлау | Мәсьәләне аңлый, гипотеза куя, материалны төркемли белергә күнегү. Логик фикерләү сәләтен үстерү | Табышмакның образлы табигате хакында гомуми мәгълүмати күзаллау булдыру, аның эстетик кыйммәтен тою хисе булдыру | Табышмакларның төзелешен өйрәнү, җавабын табу | | |
| 19-21 | Мәзәкләр | Белемнәрне тирәнәйтү, системалаштыру | Мәзәкләр. Мәзәкләрдәге тапкырлык, юмор, кимчелекләрне тәнкыйтьтирән мәгънә, хикмәтлелек | Үзаңын булдыру | Үз фикерен дәлилли, кирәк икән-үзгәртә-төгәлләштерә, нәтиҗәләр чыгара алу | Мәзәкләр жанры турында белемнәрне киңәйтү, мәзәкләрдә халыкның тапкырлыгы, шат күңеле, оста булуын күрсәтү | Мәзәкләрне уку, эчтәлеген ачыклау, сорауларга җавап бирү. Мәзәкләрдә халыкның тапкырлыгы, шат күңеле, оста булуын күрсәтү | | |
| 22 | Бәетләр. Аларның барлыкка килүе | Яңа материалны өйрәнү дәресе | Бәетләр. Аларның барлыкка килүе, мөстәкыйль жанр булып формалашуы, үсеш үзенчәлекләре | Туган халкыңа хөрмәт хисенә төшенү | Аерым билгеләрне аеру максаты белән текстларны чагыштыру. Төшенчә итеп чыгару | Бәет жанрын өйрәнү, бәетләргә хас сыйфатларны билгеләү | Үзләре укыган, ишеткән бәетләрне сөйләү, фикер алышу. Татар халкының талант ияләрен | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | бәяләү | | |
| 23 | “Сак-Сок” бәете | Яңа материалны өйрәнү дәресе | “Сак-Сок” бәетен уку, анализлау. | Туганлык, дуслык төшенчәләрен аңлау | Әңгәмәне башлый, дәвам итә, тыңлый белү. Сиземләү, тою сәләтен үстерү | “Сак-Сок” бәетен уку, анализлау. Бәеттә хис дәрәҗәсен күрсәтә белү | Бәетне уку, текстка якын килеп эчтәлеген сөйләү, сорауларга җавап бирү | | |
| 24 | Б.с.ү. Сочинение язу. “Сак-сок” бәетендә тасвирланган халык акылы һәм синең үз нәтиҗәләрең | Белемнәрне ныгыту, системалаштыру | Сочинение язу. | | Үз фикерләреңне эзлекле бәян итә белү. Сөйләм телен, язу культурасын һәм иҗади фиерләвен үстерү. Материалны аерып алу, тиешле тел калыбы табу, уку, төзәтү, төрле ярдәмлекләрдән, сүзлекләрдән файдалана белү | “Сак-сок” бәетендә тасвирланган халык акылы һәм синең үз нәтиҗәләрең” темасына сочинение язу | План төзү, план буенча сөйләү, сочинениене мөстәкыйль язу | Сочинение. | |
| 25-26 | Риваятьләр, легендалар | Яңа материалны өйрәнү дәресе | Риваятьләр, легендалар. Аларның килеп чыгышы. Аларга хас үзенчәлекләр | Сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итәргә өйрәнү | Төрле чыганыклардан танып-белү һәм коммуникатив ихтыяҗларны канәгатьләндерерлек мәгълүматлар табарга күнегү | Риваятьләр, легендалар турында мәгълүматлы булу. Теоретик белемнәр белән коралллану | Теоретик белемнәр белән коралллану, сорауларга җавап бирү, биремнәр эшләү | | |
| 27-28 | Риваятьләр, легендалар | Катнаш дәрес | Дәреслектә бирелгән риваятьләрне уку, анализлау | Милли гореф-гадәт, йолаларны тану, хыял дөньяларын баету | Риваятьләрдәге төп фикерне таба белү, дәлилләү, билгеле бер күрсәтмә нигезендә эшли белү | Риваятьләрне уку, анализлау | Риваять һәм легендаларны сәнгатьле итеп уку, алар буенча сорауларга җавап бирү, биремнәрне эшләү. Башка халык авыз иҗаты әсәрләре белән чагыштыру, сурәтләү чараларын табу | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 29-30 | Халык авыз иҗатында образлар | Практик дәрес | Халык авыз иҗатында образлар. “Образ (сурәт), поэтика” төшенчәләре бирү | Алган белемнәрне максатчан куллана белү. Фольклор әсәрләрен укуга теләк уяну | үзбәяләү | Халык авыз иҗатында образлар турында мәгълүматлы булу. “Образ (сурәт)”, “поэтика” төшенчәләре бирү | “Ак бүре”, “Үги кыз” экиятләрендәге образларны тикшерү, әңгәмәдә катнашу | Белемкүнекмәлләрне тикшерү | |
| 31 | Әдәби экиятләр | Яңа төшенчәләр формалаштыру | Әдәби экиятләр. Аларның халык авыз иҗатына нигезләнеп иҗат ителүе | Милли әдәбият белән кызыксыну булдыру | Әдәби экиятләрне халык экиятләреннән аера белү. Аларны чагыштыру. Сөйләм телен үстерү, фикерне төгәл һәм тулы итеп җиткерә белү, әңгәмә кора белү | Әдәби экиятләр турында мәгълүмат алу | Әдәби экиятләргә мисаллар китерү. Эчтәлекләрен искә төшереп сөйләү | | |
| 32 | Г.Тукай “Шүрәле” экияте | Катнаш дәре. | Г.Тукай тормышы һәм иҗаты турында белемнәрне тирәнәйтү. “Шүрәле” экиятен өйрәнү | Әсәрнең матурлыгын, үзенчәлекле сыйфатларын күрә белү | Төп образга карата башкаларның фикерен тыңлау, үз фикереңбелән чагыштыру, дәлилләү | Г.Тукай тормышы һәм иҗаты турында белемнәрне тирәнәйтү. “Шүрәле” экиятен укып анализлау. Лиро-эпик әсәрләрнең төп сыйфатларын аңлау | Экият-поэманы "автор артыннан бару" юлы белән анализлау. Поэмада вакыйгаларны, төп геройларны күрсәтү | | |
| 33-35 | Җ.Тәрҗеманов “Тукран малае Шуктуган” | Катнаш дәрес | Җ.Тәрҗеманов “Тукран малае Шуктуган” экиятен уку, фикер алышу | Үзеңдә тырышлык сыйфатлары булдыру | Әсәр буенча фикер алышу, фикерләрне төгәл һәм тулы итеп җиткерә алу | Җ.Тәрҗеманов “Тукран малае Шуктуган” экиятен дөрес аңлап уку, анализлау | Текстны уку, сорауларга җавап эзләү, экиятнең эчтәлеген аңлау, төп фикерне билгеләү | | |
| 36-38 | Ә.Фәйзи “Аучы Мәргән белән Болан кыз” | Катнаш дәрес | Ә.Фәйзи “Аучы Мәргән белән Болан кыз” экиятен өйрәнү | Хыял дөньяңны баету | Төркемнәрдә эшләү күнекмәләрен үстерү, экияттәге образлы әйтемнәрне таба белү, тексттагы төп фикерне аерып чыгара белү | Ә.Фәйзи “Аучы Мәргән белән Болан кыз” экиятен уку һәм анализлау | Экияте сәнгатьле итеп уку, сорау һәм биремнәргә җавап бирү, төп фикерне аеру | | |
| 39 | Б.с.ү. Азат | Катнаш дәрес | Азат Мәргән об- | Батырлык ту- | Тексттан иң мөһимен | Азат Мәргән об- | Экият геройларына | Язма | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Мәргән образына характери-стика бирү | | разына характери-стика бирү | рында төшенчә алу | аерып чыгара белү. Образга төрле яклап бәя бирү күнек-мәләрен үстерү. Бәйләнешле сөйләм үстерү | разына характери-стика бирү | бәя бирү, сөйләү, әңгәмәдә катнашу, язма эш башкару | эш | |
| 40-42 | Рабит Ба-тулла “Ку-рай уйный бер малай” | Катнаш дәрес | Язучы иҗатына күзәтү ясау. “Курай уйный бер малай” әкиятен укып ана-лизлау | Рухи-әхлакый сыйфатлар бул-дыру | Әкияттә бирелгән төп фикерне ачык-лый белергә өйрәнү, үз мөнәсәбәтеңне белдерү, дәлилләү | Рабит Батулла ту-рында белешмә алу, “Курай уйный бер малай” әкиятен уку һәм анализлау | Әсәр буенча әңгәмә кору, үз мөнәсәбәтләрен бел-дереп, әкиятнең эчтәлеген сөйләү | | |
| 43-44 | Ф. Яруллин тормышы һәм иҗаты. “Зәңгәр күлдә ай коена” әки-яте | Яңа белем-нәрне үзләштерү | Ф. Яруллин тор-мышы һәм иҗаты турында белешмә бирү. “Зәңгәр күлдә ай коена” әкиятен өйрәнү | Мәрхәмәтлелек, теләктәшлек, башкаларга ярдәм итү теләге хисләренә төшенү. Рухи матурлык хи-сләре булдыру | Уку мәсьәләсен аңлау һәм үтәү, бил-геле бер күрсәтмә нигезендә эшли белү, логик фикерләүләрен үстерү, үз карашла-рын раслау һәм дәлилләү | Ф. Яруллин тор-мышы һәм иҗаты турында белешмә бирү. “Зәңгәр күлдә ай коена” әкиятен уку һәм анализлау | Укытучы сөйләвен тыңлау, сорауларга җавап бирү. Язучы биографиясе буенча хронологик таблица төзү. Биремнәр эшләү. Әкият эчтәле-ге буенча бәхәстә катнашу, үз ка-рашларыңны раслау һәм дәлилләү | | |
| 45 | Ф. Яруллин “Кояштагы тап” әкияте | Катнаш дәрес | Ф. Яруллин “Кояш-тагы тап” әкиятен өйрәнү | Әниләргә хөрмәт хисенә төшенү | Әсәрнең эчтәлеген мөстәкыйль рәвештә үзләштерү һәм ана-лиз ясау күнекмәләре булдыру. Әкиятнең темасын, проблема-сы, максатын мөстәкыйль билгели алу | Ф. Яруллин “Кояш-тагы тап” әкиятен уку һәм анализлау. Әсәрдәге геройны характерлап, аның турында фикер әйтә белү | Әкиятне уку, әкият буенча сорауларга җавап бирү, би-ремнәрне үтәү, ге-ройга бәя бирү | | |
| 46 | Б.с.ү. Сочи-нение язу. Әдәби әки-ятләрдә табигать һәм кеше | Белемнәрне ныгыту, си-стемалашты-ру | Сочинение язу | Табигатьнең матурлыгына соклана белү, кешенең аны саклаудагы ро-лен аңлау | Үз фикерләреңне эзлекле бәян итә белү. Сөйләм телен, язу культурасын һәм иҗади фиерләвен үстерү. Материалны | Әдәби әкиятләрдә табигать һәм кеше образларына са-лынган фикерләр, нәтиҗәләр темасы-на сочинение язу | План төзү, план буенча сөйләү, сочи-нениене мөстәкыйль язу | Сочи чине-не-ние | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | образлары-на салынган фикерләр, нәтиҗәләр (өйрәнгән әсәрләр мисалында) | | | | аерып алу, тиешле тел калыбы табу, уку, төзәтү, төрле ярдәмлекләрдән, сүзлекләрдән файда-лана белү | | | | |
| 47 | Д.т.у. Ләбиб Лерон. Ша-ян хикәяләр, шигырьләр, экиятләр | Катнаш дәрес | Л. Лерон иҗаты белән танышу. Шаян хикәяләрен, ши-гырьләрен, экият-ләрен өйрәнү | Язучы иҗатына кызыксыну бул-дыру | Әсәрләргә карата үз фикереңне белдерә алу, дәлилләү, төп фикерне аерып чы-гара белү | Л.Лерон турында блешмә алу. Әсәрләрнең идея эчтәлеген ачыклау | Язучы әсәрләрен анализлау, аларга бәя бирү | | |
| 48 | Әдәби жанр | Яңа төшенчәләр форма-лаштыру | Әдәби әсәрләрнең төрләргә бүленеше. Эпик жанрлар ту-рында аңлату | Укуга карата теләк-омтылыш, җаваплы караш булдыру | Әдәбият белеме сүзлегеннән кирәкле терминнарны таба белү, билгеле бер күрсәтмә нигезендә эшли белү, әңгәмәдә катнашу | Әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын билгели белү | Таныш булган әсәрләрнең төрен, жанрын билгеләү, сорауларга җавап бирү, нәтиҗә ясау | | |
| 49-50 | Ф. Әмир-хан. “Ай өстендә Зөһрә кыз” хикәясе | Катнаш дәрес | Ф. Әмирхан тор-мышы һәм иҗаты турында белешмә бирү. “Ай өстендәге Зөһрә кыз” хикәсен өйрәнү | Мәрхәмәтлелек хисе турында төшенчә алу, эш сөючәнлекнең замана баласына хас сыйфат булырга ти-ешлегенә төшенү | Язучының тормыш һәм иҗат юлларын-нан төп фактларны белү. Хикәядәге күтәрелгән пробле-маларны аңлый һәм аларга карата үз фи-кереңне дәлилләп әйтә белү | Ф. Әмирхан тор-мышы һәм иҗаты турында белешмә алу. “Ай өстендәге Зөһрә кыз” хикәсен уку һәм анализлау | Хикәяне сәнгатьле итеп уку, анализлау, хис-кичерешләргә бәя бирү | | |
| 51-52 | Ф. Әмир-хан. “Нәҗип” хикәясе | Катнаш дәрес. | “Нәҗип” хикәясен уку, анализлау, хикәя турында төшенчә бирү | Әдәплелек сый-фатлары булды-ру | Укыган әсәр буенча фикер алышуда кат-нашу. Иптәшләреңне тыңлый, ә үз ка-рашларыңны матур итеп әйтә белү. Әсәр буенча дөрес нәтиҗәләр чыгару, | “Нәҗип” хикәясен уку, анализлау, хикәя турында төшенчә алу. | Әсәрне анализлау, геройларга бәя бирү, сурәтләү чараларын табу, хикәянең үзенчәлекләрен бил-геләп, төшенчә итеп чыгару | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | гомумиләштерүләр ясау | | | | |
| 53 | Б.с.ү. Сочинение "Минем яраткан һөнәрем" | Белемнәрне ныгыту, системалаштыр. | "Минем яраткан һөнәрем" темасына сочинение язу | Һөнәр, аңа ия булу кирәклеге турында аңлау | Үз фикерләреңне эзлекле бәян итә белү. Сөйләм телен, язу культурасын һәм иҗади фикерләвен үстерү | "Минем яраткан һөнәрем" темасына сочинение язу | План төзү, план буенча сөйләү, сочинениене мөстәкыйль язу | Сочи чине-не-ние | |
| 54 | Д.Т.У. Фаил Шәфигуллин-ның "Акмөгез" хикәясе | Катнаш дәрес | Ф. Шәфигуллин иҗаты. "Акмөгез" хикәясен өйрәнү | Табигатькә сакчыл караш, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек кебек сыйфатларны булдыру | Әсәргә карата үз карашың булу, дәлилле фикер җиткерә белү, тексттан кирәкле мәгълүматны аерып чыгара белү, әсәрнең эчтәлеген үз сүзләрең белән сөйли белү | Ф. Шәфигуллин иҗаты. "Акмөгез" хикәясе уку һәм анализлау | Әсәрне уку, эчтәлеген сөйләү анализлау | | |
| 55 | Мәсәл жанры | Яңа төшенчәләр формалаштыру | Мәсәл жанры. Мәсәлдә Аллегорик образлар | Татар әдәбиятына кызыксыну булдыру | Тема буенча сораулар бирә белү, сөйләм телен һәм фикерләү сәләтен үстерү. Әдәбият теориясе буенча билгеле бер күләмдә белемгә ия булу | Мәсәл жанры турында белешмә алу, мәсәлдә аллегорик образларны тикшерү | Таныш булган мәсәлләрне искә төшерү, эчтәлекләрен сөйләп карау | | |
| 56 | М. Гафури. "Сарыкны кем ашаган?" мәсәле | Катнаш дәрес | М. Гафуриның "Сарыкны кем ашаган?" мәсәлен өйрәнү | Гаделлек, дөреслек һәм аларның киресе булган сыйфатларны тану, бәяләү | Әсәрдә автор карашларын ачыклау һәм әсәргә карата үз фикереңне әйтә белү | Әсәрне иҗтимагый һәм мәдәни тормыш күренешләре белән бәйлелектә аңлау | Әсәрне сәнгатьле уку, анализлау, идеяне чыгару | | |
| 57 | Г. Тукай. "Ике сабан" мәсәле | Катнаш дәрес | Г. Тукайның "Ике сабан" мәсәлен өйрәнү | Тырышлык сыйфатларын булдыру | Сәбәп – нәтиҗә бәйләнеше булдыру, төрле фикерләрне исәпкә алып эш итә белү, үз фикерен тексттан мисаллар ярдәмендә дәлилләү | Г. Тукайның "Ике сабан" мәсәлен уку һәм анализлау | Әсәрне уку, эчтәлеген аңлау, фикер алышу, идеясен билгеләү | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 58 | Сәнгать төре булaрак әдәбият. Чәчмә әсәрләрдән сурәтләү чараларын табу | Практик дәрес | Ә. Еникинең “Бала” хикәясендә автор кулланган сурәтләү чараларын табу, анализлау | Эстетик зәвык булдыру | Укытучы куйган уку мәсьәләсен аңлау һәм үтәү. Сөйләм телен баету | Ә. Еникинең “Бала” хикәясендә автор кулланган сурәтләү чараларын табу, анализлау. Әсәрдә аларның ролен ачыклау | Хикәядәге сурәтләү чараларын табу, аларның әһәмиятен билгеләү, фикер алышу | | |
| 59 | Шигырь белән язылган әсәрнең сәнгать чараларын билгеләү | Практик дәрес | И. Юзеевның “Бер сүз” шигырендә сәнгать чараларын күзәтү | Эстетик зәвык булдыру | Укытучы куйган уку мәсьәләсен аңлау һәм үтәү, фикерне төгәл һәм дөрес итеп җиткерә белү, сөйләм телен баету | Шигырь төзелешенә хас үзенчәлекләргә төшенү | Шигырь тезмәләренең озынлыгын билгеләү; ритм, рифмаларны күзәтү, нәтиҗәләр ясау | Белемкүнекмәләрне тикшерү | |
| 60 | Д.т.у. Вакытлы матбугат басмалары | Катнаш дәрес | Балалар өчен чыгарылган газета журналларга күзәтү ясау | Мәгълүмат белән эшләү культурасы формалашу | Үз фикереңне логик эзлеклелектә әйтә белү, иптәшеңне тыңлау, бәяләү | Публицистик жанр турында мәгълүмат алу | Газета-журнал язмаларын уку, анализлау | | |
| 61 | Шигърият.Г. Тукай. “Пар ат” шигыре | Катнаш дәрес | Г. Тукайның “Пар ат” шигырен өйрәнү | Шагыйрь иҗатына хөрмәт хисләре булдыру | Сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булдыру, логик фикерләү сәләтен үстерү, шигырьдәге хисне, аны тудырган сәбәпне ачыклау, нәтиҗәләр ясау | Г. Тукай. “Пар ат” шигырен уку һәм анализлау | Әсәрне сәнгатьле итеп уку, анализлау, сурәтләү чараларын табу. Хисләр бирелешен күзәтү. Х.Якупов иллюстрациясе буенча үзара фикер алышып, әңгәмә кору | | |
| 62-63 | Г. Тукай. “Туган җиремә”, “Туган авыл” шигырьләре | Катнаш дәрес | Г. Тукай. “Туган җиремә”, “Туган авыл” шигырьләрен уку, анализлау, сурәтләү чараларын табу | Туган җиргә мәхәббәт хисләре турында төшенчә алу | Әсәр хакында дөрес фикер йөртә алу, әсәрдә автор карашларын ачыклау һәм әсәргә карата үз фикереңне әйтә белү | Г. Тукай. “Туган җиремә”, “Туган авыл” шигырьләрен уку, анализлау | Шигырьне анализлау, хис-сәбәп бәйләнешен ачыклау, сурәтләү чараларын табу | | |
| 64 | Б.с.ү. Сочинение язу. “Минем | Белемнәрне ныгыту, системалаштыру | Сочинение язу | Туган җиргә мәхәббәт хисе булдыру | Үз фикерләреңне эзлекле бәян итә белү. Сөйләм телен, | “Минем туган җирем” темасына сочинение язу | План төзү, план буенча сөйләү, сочинениене мөстәкыйль | Сочинение- | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | туган җирем” | | | | язу культурасын һәм иҗади фикерләвен үстерү | | язу | ние | |
| 65 | Ш. Галиев шигырьләре | Катнаш дәрес | Ш. Галиев тормыш юлы, иҗаты. Балалар дөньясын яктырткан әсәрләре | Шагыйрь иҗатына хөрмәт хисләре булдыру | Шигырьне дөрес аңлап уку, анализлау, билгеле күрсәтмә нигезендә эшләү. Шигырьдә автор карашларын ачыклау, үз фикерләреңне тормыш белән бәйләп күрсәтә белү | Ш. Галиев тормыш юлы, иҗаты турында белешмә алу. Балалар өчен язган әсәрләрен уку һәм анализлау | Укытучының сөйләвен тыңлау, шигырьне сәнгатьле итеп уку, фикер алышу | | |
| 66-67 | Ш. Галиев шигырьләре | Катнаш дәрес | Ш. Галиев шигырьләре. Шигырьләрдә дөньяны танып белү, тәҗрибә туплау, юмор | Шигърияткә мәхәббәт хисләре булдыру | Әдәби әсәрне эчтәлек һәм форма берлегендә аңлау, Әсәрләрне тормыш белән бәйлелектә аңлау | Ш.Галиевның балалар өчен язган әсәрләрен уку һәм анализлау | Шигырьләрне сәнгатьле уку, анализлау, төп фикерне аерып чыгару | | |
| 68 | Ф.Яруллин “Сез иң гүзәл кеше икәнсез” | Катнаш дәрес | Ф. Яруллинның “Сез иң гүзәл кеше икәнсез” шигырен уку, анализлау | Укытучыга карата хөрмәт хисләре булдыру | Әдәби әсәрне эчтәлек һәм форма берлегендә аңлау, шигырьнең идея эчтәлеген ачу, бәяләү | Ф. Яруллинның “Сез иң гүзәл кеше икәнсез” шигырен уку, анализлау | Шигырьне сәнгатьле уку, анализлау | | |
| 69 | Б.с.ү. Уку елы дәвамында өйрәнгән әсәрләрне кабатлау | Белемнәрне гамәлдә куллану | Ш. Галиев иҗаты буенча язма эш башкару | Матур әдәбиятка мәхәббәт хисе уяну | Мәгълүматны туплау, күмәк эш башкару. Сөйләм телен, язу культурасын һәм иҗади фикерләвен үстерү | Татар әдәби теле нормаларына нигезләнеп, бәйләнешле текст төзү | Укучыларның мөстәкыйль эше | Язма эш | |
| 70 | Йомгаклау дәресе | Кабатлау-йомгаклау | Уку елы буена үткәннәрне гомуми кабатлау | Милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңелдән уздырып кабул итәргә өйрәнү | Үз эшчәнлегенә, әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белүенә, мөстәкыйль карар кабул итә һәм аларны җиренә җиткереп үти алуына ирешү | Укыганнарны гомумиләштереп кабатлау | Уку елы буена үткәннәрне кабатлау, әңгәмәдә катнашу, биремнәрне эшләү | | |

**Рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәпләре**
**(V сыйныф) өчен татар әдәбиятыннан эш программасы**

(Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 5 нче с-ф. Ике кисәктә. / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. – Казан: «Мәгариф – Вакыт» нәшр., 2014. – 143 б. дәреслеге буенча)

Төзүче-авторлары: Закирова А.Ф., Казан шәһәре Вахитов районы 96 нчы гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Мифтахутдинова А.З., Казан шәһәре Вахитов районы 96 нчы гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

## Аңлатма язуы

5 нче сыйныфлар өчен татар әдәбиятыннан эш программасы Россия Федерациясендәге һәм Татарстан Республикасындагы мәгарифкә кагылышлы хокукый-норматив актларга һәм федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелде:

1. Россия Федерациясенең “Мәгариф турында”гы Законы (Федеральный закон от 29.12.2012 273-ФЗ “Об образовании в Российской Федерации”).
2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы ((Закон Республики Татарстан “Об образовании” № 68-ЗРТ от 22 июля 2013 года, статья 8).
3. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясе халыктелләре турында”гы 126-ФЗ нчы номерлы Законы (24.07.1998).
4. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы приказы, 30 нчы август, 2013 нче ел №115 (“Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – начального общего, основного общего и среднего общего образования”).
5. “Татарстан Республикасының халык телләре турында” Законы (Закон Республики Татарстан от 08.07.1992 № 1560-XII (ред. от 03.03.2012г.) “О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан”).
6. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы, 2004нче ел, 1нче июль.
7. “2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы”, 2013 нче ел, 25 нче октябрь, 794 нче карар.
8. Төп гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандарты (Россия Мәгариф һәм Фән министрлыгында 2010 нчы елның 17 нче декабрь боерыгы 1897 нче номер белән расланган, РФ Юстиция Министрлыгында 19644 нче регистрацион номеры белән 2011нче елның 1 нче февралендә теркәлгән).
9. Татарстан Республикасында 2012-2020 нче елларда фән һәм мәгариф үсеше турында “Дәүләт программасы”.
10. 2010-2015 нче елларда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү стратегиясе “Киләчәк” программасы.

5 нче сыйныф өчен “Татар әдәбияты” курсының эш программасы Федераль дәүләт белем бирү стандартларының таләпләренә туры китереп, “Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары (V-IX сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа” (Ф.Х.Җәүһәрова, К.С.Фәтхуллова. Казан, 2013) һәм “Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү оешмаларының татар сыйныфлары өчен татар әдәбиятыннан программа” (Төзүче-авторлар: Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина), 5 нче сыйныф өчен Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллиналар эшләгән (Казан, Мәгариф – Вакыт, 2014), Татарстанның Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслеккә нигезләнеп төзелде.

Дәреслек: Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 5 нче с-ф. Ике кисәктә. / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. – Казан: «Мәгариф – Вакыт» нәшр., 2014. – 143 б.: рәс. б-н.

## Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына әдәбият укытуның төп максаты һәм бурычлары

1. Укучының татар әдәби телен үзләштерүенә, текстны аңлап, сәнгатьле итеп, йөгерек укуына, дөрес яза белүенә, әдәби тел нормаларын саклап, төрле темаларга иркен сөйләшүенә ирешү, матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку күнекмәләре формалаштыру, телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерү.
2. Балаларны татар әдәбияты, халык авыз иҗаты, татар халкының җыр-музыкасы, сынлы сәнгате белән таныштыру, күренекле язучылар һәм аларның әсәрләрен үзләштерүләренә ирешү, матур әдәбият әсәрләрен (яки әдәби әсәрләрдән өзекне) укып үзләштерү, алар турында үз фикерләрен әйтергә өйрәтү.
3. Әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлату һәм кулланырга өйрәтү.
4. Укучыларга татар халкының килеп чыгышы, тарихи язмышы, милләттәшләребез тормышы турында мәгълүмат бирү.
5. Халык тарихын һәм мирасын өйрәнү аша укучыларда Ватанга, халыкка, туган телгә мәхәббәт, олыларга, кечеләргә һәм гомумән кешегә ихтирам, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек тәрбияләү. Эстетик тәрбия бирү, табигатькә сакчыл, мәрхәмәтле караш уяту.
6. Татар, рус һәм башка халыклар әдәбиятларын чагыштырып карау күнекмәләре булдыру.
7. Әдәби әсәрләрне өйрәнү барышында укучыларны сәнгатьле уку алымнарына өйрәтү дә әһәмиятле. Бу җәһәттән эш түбәндәге юнәлешләрдә алып барыла:
   - татар теленең үзенчәлекле авазларын әйтү күнекмәләре булдыру;
   - сүз басымын дөрес куя белү;
   - логик басымны дөрес куя белү;
   - җөмләне фразаларга бүлү һәм дөрес пауза белән уку;
   - тавышны дөрес төшерә һәм күтәрә белү, ягъни интонацияне дөрес куллану күнекмәләре булдыру һ.б.

Программада ятлау өчен әсәрләр тәкъдим ителә, укучыларның уку сыйфатын билгеләү максатында, әдәби әсәрләр белән эшләүгә, әдәбият теориясеннән белем-күнекмәләр булдыруга таләпләр бирелә. Матур әдәбиятны төрле яклап өйрәнү һәм үзләштерү укучыларның сөйләм һәм язу күнекмәләрен камилләштерергә ярдәм итә. Шуңа күрә урта белемгә ия булган яшьләр ана телендә ачык фикерле, иркен сөйләшә, дөрес яза белергә тиеш.

## Уку фәненең уку планында тоткан урыны

Мәктәптә әдәбият предметы – кирәкле, әһәмиятле предметларның берсе. Ул укучыларны тормышны үзенчәлекле итеп танып белергә өйрәтә, хисси-эмоциональ дөньясын баета, эстетик зәвык тәрбияли, сөйләмен үстерә, гомумән, шәхес итеп тәрбияләүдә зур роль уйный.

Татар әдәбияты төп мәктәптә 5-9 сыйныфларда өйрәнелә. Укыту планында каралганча, татар әдәбияты дәресләре өчен 5 нче сыйныфта 2 сәгать исәбеннән елга 70(35) сәгать күздә тотыла.

## Укытуның көтелгән нәтиҗәләре

- сүз сәнгатенең образлы табигатен тою;
- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлау;
- классик әдипләрнең (К.Насыйри, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, М.Җәлил) биографик белешмәләре белән танышу;
- өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истә калдыру;
- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү;
- әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
- укыган әсәрнең темасын, проблемасын билгеләү;
- геройларга характеристика бирү;
- сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен ачу;
- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;
- укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү;
- әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
- кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
- өйрәнелгән әсәрләргә бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү;
- укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерне дәлилле белү;
- татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;
- эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү;
- аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, интернет чаралары һ.б. аша эзләү.

## Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

- шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү, күпмилләтле илебезгә карата ярату хисләре, татар әдәбиятына һәм башка халыклар әдәбиятына, мәдәниятына ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру;
- активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә, акыл һәм рухи эшчәнлеккә өйрәнү, шәхес буларак формалашуны дәвам итү;
- үзең белән идарә итүгә юнәлдерелгән белем һәм күнекмәләрне тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү, тормышта үз урыныңны күзаллый башлау;
- милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру.

### Метапредмет нәтиҗәләр

“Әдәбият” курсын өйрәнүнең метапредмет нәтиҗәләре булып, универсаль уку-укыту гамәлләре формалаштыру санала (УУГ.)

**Танып белү УУГ(ТБУУГ):**

- укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра белүе, бәяләү;
- мөстәкыйль рәвештә төрле текстларны укый белү, өстәмә материалларны таба һәм тиешле урында куллана белү;
- кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү;
- татар әдәбиятын рус әдәбияты, башка халыклар әдәбиятлары белән бәйләп укып, әдәбиятлар арасындагы уртак проблемаларны, уртак кыйммәтләрне күрсәтү аша, дөнья культурасы белән танышу;
- бәхәсләшү, үз фикерен дәлилләү, анализ ясау, йомгаклау.

**Коммуникатив УУГ (КУУГ):**

- төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;
- күмәк эш вакытында бер фикергә килә белү;
- коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы ролен билгеләү;
- үз фикереңне телдән һәм язма формада җиткерә белү;
- текст буенча сораулар куя белү
- бәхәсләшү, үз фикерләрен дәлилләү.

**Регулятив УУГ (РУУГ):**

- мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын һәм максатларын формалаштыру;
- проблеманы аңлый белү, гипотеза чыгару, материалны төзү, үз фикереңне раслау өчен дәлилләр сайлый белү, нәтиҗәләрне формалаштыру;
- уку проблемасын чишү өчен план төзү;
- укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү.

### Предмет нәтиҗәләре

- төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади уку;
- әдәби әсәрләрне анализлау, аларның билгеле бер жанрга каравын, теманы аңлау һәм формалаштыру, идеясен тотып ала белү;
- геройларга характеристика бирү, төрле әсәрдәге бер яки берничә герой белән чагыштыра белү;
- татар әдәбияты һәм мәдәниятенең әхлакый һәм рухи кыйммәтләрен үзара якынайту, башка халыкларныкы белән чагыштыру;
- төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне ишетеп кабул итү, аңлаешлы уку, эчтәлекне дөрес аңлау;
- әдәбиятның образлы дөньясын сүз сәнгате күренеше буларак аңлау, әдәби әсәрләрнең эстетик ягын кабул итү, әсәрләрдән рухи тәм табу.

### Курсның эчтәлеге

### Кереш

Ибраһим Газинең китап турындагы “Үзе бер могҗиза” әсәрен укып фикер алышу. Дәреслекнең төзелеше, структурасы – тышлык, титул бите, форзац, шартлы билгеләр, эчтәлек, дәреслекне төзүчеләр: автор, рәссам, редактор, корректор, нәшир һ.б. белән танышу.

Китап турындагы мәкаль, табышмаклар, кызыклы мәгълүматлар.

**Халык авыз иҗаты**

Фольклор – күмәк халык авыз иҗаты. Фольклорның кече жанрлары. Балалар фольклор (табышмак, такмак, сынамыш, мәсәл һ.б.) турында кабатлау. Бишек җырлары (халык авыз иҗаты белән беррәттән, авторлар иҗат иткән бишек җырларын да өйрәнү).

Әдәбият теориясе. Халык авыз иҗаты.

**Татар халык әкиятләре**

Халык авыз иҗаты буларак әкиятләр. Тылсымлы, хайваннар турындагы, тормыш-көнкүреш әкиятләре. Әкият геройлары үрнәгендә шәфкатьлелек, миһербанлылык тәрбияләү.

“Ак байтал” – тылсымлы әкият. Ат турында мәкальләр. Атка мәдхия.

Тылсымлы әкиятләрнең поэтикасы. Тылсымлы әкиятләрдә фантастик элементлар.

“Үги кыз” – тормыш-көнкүреш әкияте. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәт. Яхшылыгыңның да, начарлыгыңның да үзеңә кире кайтуы.

“Хәйләкәр төлке” – хайваннар турындагы әкият.

“Солдат боткасы”, “Өч каләм”, “Камыр батыр”, “Кәтән Иваныч” әкиятләренең кайсы төргә керүен һәм нинди билгеләре буенча төркемләнүен ачыклау.

Әдәбият теориясе.

Әкият. Әкият төрләре. Әкиятнең төзелеше. Даими эпитетлар. Гипербола. Чагыштырулар. Кабатлаулар. Инверсия. Әкияттә башлам, бетем, кульминация, чишелеш, төенләнеш, үстерелеш элементлары. Халык әкиятләренең вариативлыгы. Әкият геройлары, ярдәмче геройлар.

**Халык иҗаты белән рухланып**

Халык иҗаты әсәрләренә таянып, язучылар иҗат иткән мәсәлләр, Г.Тукай һәм Ә.Исхак,Г.Тукай һәм И.Крылов, Г.Тукай һәм Г.Шамуков язган исемдәш мәсәлләр. Уртак һәм аермалы яклары. Мәсәлләрне сәнгатьле уку.

Әдәбият теориясе.

Мәсәл жанры, читләтеп әйтү, сюжеты. Мәсәлләрдә хикәяләү, мораль. Киная. Аллегория. Мәсәл төзелеше. Бу жанрда иҗат итүчеләр.

**Хәзинә. Борынгы әдәбиятыбыз үрнәкләре**

Кол Гали турында белешмә. Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән данлыклы “Кыйссаи Йосыф” әсәре турында. Поэмадан өзекләр уку. Әсәрнең сюжеты.

Шәүкәт Галиевның Кол Галигә багышланган шигыре.

**Казан ханлыгы әдәбияты үрнәкләре**

Мөхәммәдьяр турында белешмә. “Нуры содур” поэмасыннан өзек уку. Хикәятнең мәгънәсе: игелекле эш-гамәлләр һич тә юкка чыкмый, ә бәлки артыгы белән кире үзеңә кайта.

**XIX йөз әдәбияты**

Каюм Насыйри, тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру. “Патша белән карт”, “Бай белән хезмәтче”, “Аңгыралык бәласе” әсәрләренең халык авыз иҗатына нигезләнеп язылуы.

“Әбүгалисина”. Белем алуның әһәмияте. Күңеле яхшылыкта булып, халыкка ярдәм итәргә теләгән Әбүгалисина һәм игезәге Әбелхарисның белем алырга омтылышлары. Тормыш юлларының аерылу сәбәпләре.

Каюм Насыйри музее.

**XX йөз башы татар әдәбияты**

Габдулла Тукай. Шагыйрьнең тормыш юлы турында кыскача белешмә. Башлангыч сыйныфларда шагыйрь турында өйрәнгәннәрне тирәнәйтү. ”Су анасы”, “Эш беткәч уйнарга ярый” әсәрләре. Кырлайдагы Тукай музее. Нәзыйрә жанры турында төшенчә.

**XX йөз татар әдәбияты**

Галимҗан Ибраһимов. Әдипнең тормыш юлы турында кыскача белешмә. “Яз башы”, “Фагыйлә” хикәяләре. Туган як табигатенең матурлыгы, аның белән хозурлану темаларының күтәрелүе һәм сәнгатьчә хәл ителеше. Хикәя турында төшенчә.

Муса Җәлил. Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Алтынчәч” либреттосыннан арияләр тексты.

Әдәбият теориясе: ария, либретто, строфа турында төшенчә, лирик герой.

**Сугыш чоры әдәбияты**

Муса Җәлил. “Кызыл ромашка”, “Җырларым”, “Бүреләр”.

Баллада жанры.

Харис Якуповның “Хөкем алдыннан” картинасы.

Рафаэль Мостафинның шагыйрьнең балачак елларын чагылдырган “Балыкчы Муса” хикәясе.

Фатих Кәрим. “Кыр казы”, “Ватаным өчен”. Ватан азатлыгы өчен көрәшкән солдат батырлыгы. Г.Кутуй, А.Алиш, С.Хәкимнәрнең тормыш юллары, әсәрләре. А.Пластовның “Фашист самолеты очып үтте” картинасы. Ләбиб Леронның “Фашист очып үтте” шигыре.

**Сугыштан соңгы чор әдәбияты**

Ренат Харис. “Ветеран дәфтәрләре” шигыре. Сугыш чоры язмалары.

Метафора, чагыштыру.

Фатих Хөсни. “Чыбыркы” хикәясе. Һөнәр сайлау проблемасы.

Роберт Әхмәтҗанов. “Солдатлар” шигыре. Сугыш яраларының онытылмавы.

Нәби Дәүли. “Бәхет кайда була?” шигыре. Хезмәт яраткан кешенең бәхетне табуы. Бала психологиясенең бирелеше.

Фәнис Яруллин. “Зәңгәр күлдә Ай коена” әкияте. Яхшылыкка каршы яхшылык белән җавап бирү. Эчке матурлыкның ямьсезлекне җиңүе.

Резеда Вәлиеваның “Бәхет” шигыре. Бәхет төшенчәсе. Туган илеңдә уку, эшләү – чын бәхет.

**Туган ил, туган як**

Нәкый Исәнбәт. “Туган ил” шигыре.

Туган як турында картиналар.

Нәҗип Мәдьяров. Тормыш юлы турында кыскача белешмә. “Сиңа кайттым, гүзәл туган җирем” шигыре.

Сибгат Хәким. “Бер горурлык хисе”, “Башка берни дә кирәкми” шигырьләре.

Фоат Садриев. “Тургай ни дип җырлый?” хикәясе. ЭльмираШәрифуллина. “Татарстан шуннан башлана” шигыре.

Гөлшат Зәйнәшева. “Үз илемдә” шигыре.

Резеда Вәлиева. Шагыйрәнең тормыш юлы турында кыскача белешмә. “Табигать баласына” шигыре.

М.Әгъләмов. Тормыш юлы турында кыскача белешмә. “Матурлык минем белән” шигыре.

Гамил Афзал. “Туган җиреңнән китмә” шигыре.

Разил Вәлиев. “Туган телдә дәшсәм генә” шигыре.

Кадыйр Сибгатуллин. “Шишкин наратлары” шигыре.

Иван Шишкинның “Нарат урманы” картинасы.

**Тәрҗемә әсәрләр**

А.Платонов. “Ягъфәр бабай” хикәясе (Ф.Хәсәнова тәрҗемәсе).

Дж.Родари. “Әбинең кошчыклары” хикәясе (Зөлфәт тәрҗемәсе).

А.Экзюпери. “Нәни принц” әсәре (Р.Вәлиев тәрҗемәсе).

**Язучылар иҗатында юмор**

Алмаз Гыймадиев. “Телефонлы кәҗә”, “Интернетта ALF”, “Дианаларда кунакта” хикәяләре.

Ләбиб Лерон. “Зөһрә кыз – безнең авылдан” хикәясе, “Песи булсаң иде” шигыре.

Роберт Миңнуллин. “Уйлап табучы”, “Мин әгәр икәү булсам” шигырьләре.

Шәүкәт Галиев. “Борау”, “Эш кушып булмый” шигырьләре.

Рафис Корбан. “Үзем” шигыре.

Фәнис Яруллин. “Җыр калдырыйк” шигыре.

Әдәбият теориясе: лирик герой, юмор, эпиграф, пародия.

**Рус мәктәбендә укучы татар балаларына әдәбияттан тәкъдим ителгән әсәрләр минимумы**

**(төз. Ф.Х.Җәүһәрова, К.С.Фәтхуллова)**

1. К.Насыйри “ Патшабелән карт”;
2. Г. Тукай “Су анасы”;
3. Г. Ибраһимов “Яз башы”;
4. М. Җәлил “Алтынчәч”;
5. Ф.Кәрим “Кыр казы”;
6. Ф. Хөсни “Чыбыркы”;
7. Ф. Яруллин “Зәңгәрткүлдә ай коена”;
8. М.Әгъләм “Матурлык минем белән”;
9. Н.Дәүли “Бәхет кайда була ул?”.

Биографик белешмәләр.

1. К. Насыйри
2. Г. Тукай
3. Г. Ибраһимов
4. М. Җәлил

Рус язучыларының тәрҗемә әсәрләре.

А. Платонов “ Ягъфәр бабай”.

Ятлау өчен тәкъдим ителгән әсәрләр

(авторлар тәкъдиме буенча)

1. Г.Тукай “Су анасы”;
2. С.Хәким “Бер горурлык хисе”;
3. Ф.Кәрим “Сөйләр сүзләр бик күп алар...”;
4. Н.Дәүли “Бәхет кайда була?”;
5. Ш.Галиев “Борау”;
6. М.Әгъләмов “Матурлык минем белән”;
7. Э.Шәрифуллина “Бишек җыры”.

## Тематик планлаштыру

| № | Төп темалар | Уку-укыту эшчәнлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Халык авыз иҗаты | Халык авыз иҗаты турында белемнәрне тирәнәйтү, системалаштыру, фольклор төрләрен искә төшерү, дәреслектә бирелгән таблица өстендә эшләү | 2 |
| 2 | “Ак байтал” әкияте | Әкият турында булган белемнәрне тирәнәйтү, әңгәмәдә катнашу. Әкиятне уку, эчтәлеген ачыклау | 2 |
| 3 | Тылсымлы әкият һәм аның геройлары | Тылсым төшенчәсе белән танышу, әкият геройларына бәя бирү, гомумиләштереп нәтиҗәләр чыгару | 1 |
| 4 | “Үги кыз ” әкияте | Әкиятне уку, әкияттәге уңай һәм тискәре геройлар турында сөйләшү; рольләргә бүленеп уку; бу әкиятне рус халык әкияте белән чагыштыру | 1 |
| 5 | “Хәйләкәр төлке”, “Солдат балтасы” әкиятләре | Укыган әкиятләрнең кайсы төркемгә керүен ачыклау; төп геройларны, сюжетын, башлам һәм бетем өлешләрен табу; хәйләкәр геройга характеристика бирү | 1 |
| 6 | “Камыр батыр” әкияте | Әкиятне уку; эчтәлеге буенча әңгәмә кору; герой турында сөйләшү; иллюстрациясе буенча эшләү | 1 |
| 7 | “Өч каләм” әкияте | Әкиятне уку, сюжетын ачыклау; әкиятнең төрен билгеләү; рәсемнәргә карап, дию турында белгәннәрне сөйләү | 1 |
| 8 | Мәсәлләр. Г.Тукай, Ә.Исхак, И.Крылов, Г.Шамуков мәсәлләре | Мәсәл фикер алышу; мәсәлләрне укып чагыштыру, мәсәлләрнең охшаш һәм аермалы якларын табу | 3 |
| 9 | Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәре | Әсәрдән өзек уку; сораулар буенча эчтәлекне ачыклау; әсәрдән әкияти сюжетларны табу, борынгы, мәгънәләре аңлашылмаган сүзләрне дәфтәргә язу | 2 |
| 10 | Ш.Галиев. “Кол Галигә” шигыре | Шигырьне уку, фикер алышу; Кол Галигә Ш.Галиев биргән бәяне уку | 1 |
| 11 | Мөхәммәдъяр иҗаты | Дәреслектә бирелгән текстны уку; хикәятне уку, сораулар буенча эчтәлекне ачу; әсәрдә күтәрелгән проблемаларны табу | 1 |
| 12 | К.Насыйри иҗаты. “ Әбүгалисина” әсәре | Әсәрләрне укып, фикер алышу; геройларга характеристика бирү, “Әбүгалисина” әсәрен бүлекләп уку, һәр бүлеккә исем бирү; әсәр эчтәлеге буенча план төзү, сөйләү | 3 |
| 13 | Г.Тукай - татар халкының бөек шагыйре. “Су анасы” әкият-поэмасы | Дәреслек өстендә эш; иллюстрация буенча сөйләшү; әкият-поэманы уку; Су анасын тасвирлап сөйләү; Тукай турында язучылар фикерен уку | 1 |
| 14 | Г.Ибраһимов “Яз башы”, “Фәгыйлә” хикәяләре | Хикәяләрне уку; фикер алышу; анализлау, тексттан мисаллар табып уку | 2 |
| 15 | М.Җәлил. “Алтынчәч” либреттосы | Язучы биографиясен уку; арияләрне уку; поэманың геройлары турында сөйләшү, уңай һәм тискәре геройларның төп сыйфатларын табу; рифма төрләрен искә төшерү | 3 |
| 16 | М.Җәлил. “Кызыл ромашка”, “Җырларым”, “Бүреләр” шигырьләре | Шигырьләрне уку, эчтәлеге буенча әңгәмә; җырның көче турында сөйләшү; дәреслектә бирелгән рәсем буенча эшләү | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 17 | М.Җәлил музейларына сәяхәт | Төркемнәрдә эшләү; музейлар турында сөйләү; дәреслектәге материалны уку | 1 |
| 18 | Ф.Кәрим. “Кыр казы”, “Ватаным өчен” шигырьләре | Әсәрләрдән ясалган күргәзмәне карау; шигырьләрне уку, чагыштыру, уртак һәм аермалы якларны табу | 1 |
| 19 | Ф.Кәрим. “Гармунчы Аю белән җырчы Маймыл” әсәре | Әкият аермалы якларын табу, иң кызыклы җавапны ачыклау төрләрен кабатлау; әсәрне уку; әкиятнең халык әкияте белән уртак һәм | 1 |
| 20 | Г.Кутуй. “Сагыну” нәсере | Дәреслектәге материалларны уку; эчтәлек буенча әңгәмә оештыру; сагыну турында сөйләшү; әсәрдәге географик атамаларны табу, картадан күрсәтү | 1 |
| 21 | А.Алиш. “Килделәр” хикәясе | Хикәяне уку, эчтәлеген ачыклау; әсәр буенча план төзү; анализлау | 1 |
| 22 | С.Хәким. “Колын” шигыре. С.Хәким музеена сәяхәт | Дәреслектә бирелгән автобиографик текстны уку; шигырьне уку һәм анализлау; “Сугышта атлар да көрәште” дигән темага сөйләшүдә катнашу; атлар турындагы әсәрләрне искә төшерү | 1 |
| 23 | Р.Харис. “Ветеран дәфтәрләр” шигыре | Шигырьне уку, анализлау, әңгәмә, метафораны кабатлау; тема буенча тест эшләү | 1 |
| 24 | Ф.Хөсни. “Чыбыркы” хикәясе | Хикәяне уку; дәреслектәге сорауларга җавап бирү; әсәр буенча язма эш башкару | 2 |
| 25 | Роберт Әхмәтҗанов. “Солдатлар” шигыре | Солдат тормышы турында сөйләшү; шигырьне сәнгатьле итеп уку; текст ахырындагы сорауларга җавап бирү; Идел һәм Дунай елгалары турында искә төшерү; җыр тыңлау | 1 |
| 26 | Н.Дәүли. “Бәхет кайда була?” шигыре, “Кар нинди җылы” хикәясе | Дәреслектән биографик белешмәне уку; проблемалы сорауга җавап эзләү; бәхет, хезмәт турында мәкальләрне укып, мәгънәләрен аңлау; төркемнәрдә эшләү | 2 |
| 27 | Ф.Яруллин. “Зәңгәр күлдә Ай коена” әкияте | Текст өстендә эшләү; “Ай” дип башланып киткән кыз һәм малай исемнәре язу; бу әкиятнең халык әкиятеннән аермасын табу; әсәрдән сурәтләү чараларын табу | 1 |
| 28 | Кеше кайчан бәхетле була? | Шигырьләрне уку; темаларын билгеләү; строфалардагы аралаш рифмаларны язып алу; тема буенча тест эшләү | 1 |
| 29 | Н.Исәнбәт. “Туган ил” шигыре | Шигырьне уку, анализлау, сорауларга җавап бирү, строфалардан туган җирне ярату турында эзләү; картиналар белән эшләү | 1 |
| 30 | Э.Шәрифуллинаның һәм Г.Зәйнашеваның туган якка багышланган шигырьләре | Туган ил турындагы шигырьләрне уку, чагыштыру; строфалар тәртибен ачыклау, кабатланып килгән юлларны табу, дәреслектә бирелгән биремнәр белән эшләү | 1 |
| 31 | Н.Мадьяров. “Сиңа кайттым, гүзәл туган җирем” шигыре | Авторның биографиясен уку һәм нинди һөнәр кешеләре булып эшләвен ачыклау; шигырьдән кабатланып килгән юлларны, эндәшләрне табу; риторик эндәшне ачыклау | 1 |
| 32 | С.Хәким. “Бер горурлык хисе”, “Башка берни дә кирәкми” шигырьләре” | Текстны сәнгатьле уку, шигырь ахырындагы сорауларга җавап бирү; элекке һәм хәзерге Татарстан турында чагыштырып сөйләү | 1 |
| 33 | Ф.Садриев. “Тургай ни дип җырлый?” әсәре | Әсәр белән картина өстендә эшләү; уртаклыкларны табу | 1 |
| 34 | Р.Вәлиева. “Табигать баласына” | Китап күргәзмәсен карау; шигырьне укып, ритм, рифмасын табу; кызыл китапка кертелгән үсемлекләр турында сөйләшү | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 35 | М.Әгъләмов. “Матурлык минем белән” шигыре | Шигырьне строфалап уку, кабатланып килгән юлларны тикшерү; мини-сочинение язу | 1 |
| 36 | Туган як турында – шагыйрьләр | Шигырьләрне укып анализлау; текст ахырындагы биремнәрне үтәү; тема буенча өйрәнгән шигырьләрне кабатлау, исемнәрен, авторларын язып алу | 1 |
| 37 | А.Платонов. “Ягъфәр бабай” әсәре | Дәреслектән автор турындагы юлларны уку; әсәрне уку; сүзлек белән эшләү; план төзү, эчтәлек сөйләү | 1 |
| 38 | Дж.Родари. “Әбинең кошчыклары” хикәясе | Текстны уку, дәреслектә бирелгән сораулар буенча эшләү | 1 |
| 39 | А.Гыймадиев хикәяләре | Хикәяләрне уку; интернет-сүзлек белән эшләү; хикәяләрдә юморны табу | 2 |
| 40 | Шәүкәт Галиев шигырьләре | Шигырьләрне уку, юмор бирелгән урыннарны табып уку, фикер алышу; “Татар исемнәре ни сөйли?” китабыннан “гәүһәр” сүзенең мәгънәсен эзләп табу | 1 |
| 41 | Л.Лерон. “Зөһрә кыз – безнең авылдан” хикәясе, “Песи булсаң иде” шигыре | Әсәрләрне уку, әкият һәм чынбарлык элементларын табу; гиперболаларны эзләү; юмор элементларын табу; эпиграф төшенчәсен аңлату | 2 |
| 42 | Р.Миңнуллин, Р.Корбан иҗатларында юмор | Шигырьләрне уку, иң оста укучыны билгеләү; сораулар өстендә эшләү | 1 |
| 43 | Бәйләнешле сөйләм үстерү | Телдән һәм язма телләрен үстерү максатыннан төрле биремнәр эшләү, тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, иҗади эш башкару. Сочинение язу | 8 |
| 44 | Сыйныфтан тыш уку | Дәрестән тыш әдәби әсәрләр уку, аларның эчтәлеген сөйли алу | 4 |
| 45 | Ф.Яруллин. “Җыр калдырыйк” шигыре. Йомгаклау дәресе | Уку елы буена үткәннәрне кабатлау, әңгәмәдә катнашу, нәтиҗә ясау | 1 |
| | Барлыгы: | | 70 |

### Укытуны матди-техник яктан һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү

Укытуны матди-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү нигезенә түбәндәгеләр кирә:

- белем һәм тәрбия бирү өчен барлык шартлар да тудырылган, санитария һәм янгыннан саклану нормаларына туры килгән уку бинасы булу;
- әдәбиятны өйрәнү өчен җитәрлек күләмдә дәреслекләр һәм өстәмә методик ярдәмлекләр белән тәэмин ителгән китапханә;
- электрон китапханә, башка электрон ресурслар, татарча сайтлардан куллану мөмкинлеге булган компьютер классы;
- лингафон кабинеты;
- электрон һәм басма күрсәтмә әсбаплар, дәреслекләр;
- мультимедиа укыту программалары, компьютер программалары;
- укучыларының белемнәрен тикшерү программалары;
- төрле типтагы сүзлекләр, энциклопедияләр;
- белешмә материаллар;
- балалар өчен чыгарылган газета һәм журналлар;
- интерактив тикшерү программалары;
- татар сайтлары (belem.ru; tatarile.org.com).

### Татар әдәбияты предметын укыту барышында укытучыга куллану өчен өстәмә әдәбият исемлеге


1. Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Г.Әхмәдуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1990.
2. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек. 2 томда / төз. Р.Даутов, Р.Рахмани. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2009.
3. Дастаннар. – Казан: Мәгариф, 2001.
4. Даутов Р.Н., Гамбәров Н.Г. Балачак әдипләре: биобиблиографик белешмәлек. 4 китапта. – Казан: Мәгариф, 2002, 2004, 2005, 2008.
5. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәр: өйрәнәбез һәи анализ ясыйбыз / Д.Заһидуллина, М.Ибраһимов, В.Әминева. – Казан: Мәгариф, 2007.
6. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау / Д.Заһидуллина, М.Ибраһимов, В.Әминева. – Казан: Мәгариф, 2005.
7. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы: Методик кулланма. – Казан: Мәгариф, 2000.
8. Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек. 2 томда. – Казан университеты, 2011.
9. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре. 3 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2010.
10. Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек: элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияты буенча кыскача белешмәлек. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2001.
11. Саттаров Г.Ф. Исемең матур, кемнәр куйган? – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989.
12. Татар әдәбияты. Теория. Тарих. / Д.Заһидуллина, Ә.Закирҗанова, Т.Гыйләҗев, Н.Йосыпова. – Казан: Мәгариф, 2006.
13. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1977, 1979, 1981.
14. Урманче Ф.И. Татар халык иҗаты. – Казан: Мәгариф, 2005.

**Күрсәтмә материаллар**

- Электрон ресурслар: “Бала” китапханәсе, “Татар мультфильмнары”, мультимедиа укыту программалары; электрон китапханә; татар сайтлары (belem.ru, tatarile.org.com); аудио һәм видео әсбаплар:
- Габдулла Тукай. Интерактив мультимедиа уку-укыту әсбабы.
- Габдулла Тукай. Энциклопедия. Дисклар коллекциясе.
- «Габдулла Тукай», «Вамин» Татарстанның мәдәни традицияләрен саклау һәм үстерү фонды, DVD и 1 CD дан торган җыентык, 2009.
- Классик әдәбиятыбыз үрнәкләре. Татар әдәбиятыдәресләренә фонохрестоматия (5-11 сыйныфлар). CD 4 форматлы. Төзүчесе: Газимҗанова Р.Г.
- Шигърият бакчасында. Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия (5-11 сыйныфлар) CD 1, CD 2, CD 3 форматлы. Төзүчесе: Газимҗанова Р.Г.
- Фәнис Яруллин. Тормышы һәм иҗатына багышланган методик әсбап. Мультемедиа басма.
- Язучыларыбыз чыгышлары һәм алар турында истәлекләр. Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия (5-11 сыйныфлар). CD5 форматлы. Төзүчесе: Газимҗанова Р.Г.
- Язучылар, композиторлар һәм рәссамнар чыгышлары, алар турында истәлекләр. Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия (5-11 сыйныфлар). CD 6 форматлы. Төзүчесе: Газимҗанова Р.Г.

## Кушымта
## Календарь-тематик план[1]

| № | Дәрес темасы | Дәрес тибы | Төп эчтәлек | Планлаштырыла торган нәтиҗәләр | | | Укучылар эшчәнлеге төрләре | Контрольнең төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | шәхескә кагылышлы | метапредмет | предмет | | | план | факт |
| 1 | Б.с.ү. Китап дигән могҗиза | Сөйләм үстерү дәресе | Дәреслек белән таныштыру; китап турында фикер алышу; китап турында мәкаль-әйтемнәр уку | Тормышта белемнең кирәклеген, китапның могҗиза икәнлеген аңлау | Дәреслеккә укучы күзлегеннән бәя бирү; тексттан билгеләнгән өзекне табу, үз фикереңне тулы һәм төгәл әйтә белү | И.Газинең “Үзе бер могҗиза” әсәрен укып анализлау | Дәреслектә ориентлаша белү, шартлы билгеләр “тел”ен өйрәнү, аңлашылмаган сүзләрне сүзлек дәфтәренә язу, үз фикерен белдерү | | | |
| **Халык авыз иҗаты** | | | | | | | | | | |
| 2-3 | Татар халык авыз иҗаты | Катнаш дәрес | Халык авыз иҗатына гомуми күзаллау булдыру, әкият турында төшенчә бирү | Татар халык авыз иҗатының кыйммәтен аңлау; матурлыкны тоя алу; гамәлләрдән чыгып, үзеңә дәрес алу | Төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне ишетеп кабул итү, аңлаешлы уку; төрле фикерләрне исәпкә алу, үз позицияңне аңлату | Фольклор жанры турында белешмә алу, әкият төшенчәсен аңлау, аның төрләре, төзелеше белән танышу | Фольклор төрләрен искә төшерү, дәреслектә бирелгән таблица өстендә эшләү; үзләре теләгән әкиятләрнең башлам, төенләнеш, вакыйгалар үсеше, кульминация һәм бетем өлешләрен табу | | | |
| 4-5 | “Ак байтал” әкияте | Катнаш дәрес | «Ак байтал» әкияте белән танышу. | Халык әкиятләренә, әкият | Әдәби текстны аңлау, анализлау, кирәк | “Ак байтал” әкияте белән танышу; халык әкияте, әкият | Әкиятне чылбыр буенча уку; Ф.Ризаеваның | | | |

[1] Укыту-методик тәэмин итү буларак укытучы календарь-тематик планны бирә ала.

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Әкиятне уку | геройлары булган хайваннарга хөрмәт, ярату хисләре белән карарга кирәклеген аңлау | өлешләрен генә аерып ала белү; бер мәгълүматны икенче төрлегә үзгәртә белү | геройлары төшенчәләрен аңлау; сәнгатьле уку | әкияткә ясалган иллюстрациясен карау, анализлау, текст белән чагыштыру | | | |
| 6 | Тылсымлы әкият һәм аның геройлары | Дәрес-диалог | Тылсымлы әкиятләр турында гомуми күзаллау булдыру, әкият геройлары белән танышу | Тылсым тормышның бизәге икәнен аңлау; матурлыкны күрә белергә, ярата белергә кирәклеген аңлау | Мөстәкыйль рәвештә төрле текстларны укый белү; әдәби әсәрләрне анализлап, геройларга характеристика бирә белү; монологик сөйләмне куллана белү | Р.Харисның әкият геройлары турындагы мәкаләсе белән танышу; тылсым төшенчәсе белән танышу | Р.Харисның әкият геройлары турындагы мәкаләсен уку; сорау һәм биремнәрне үтәү; Зәрия Хәбипованың атка мәдхиясен уку; ат турында мәкальләр уку, мәгънәләрен үз сүзләре белән аңлату | | | |
| 7 | “Үги кыз” әкияте | Дәрес-әңгәмә | «Үги кыз» татар халык әкиятен өйрәнү, эчтәлеген үзләштерү | Яхшылык һәм начарлыкның кеше тормышына йогынтысын аңлау; гамәлләрдән чыгып, үзеңә дәрес алу. | Татар һәм рус әдәбияты әкиятләрен чагыштырып, мөстәкыйль нәтиҗә ясый белү; әңгәмә кора белү; төрле әдәбиятлар арасындагы уртак проблемаларны күрсәтә белү | Татар халкының “Үги кыз” әкияте белән танышу | Әкиятне уку, әкияттәге уңай һәм тискәре геройлар турында сөйләшү; рольләргә бүленеп уку; бу әкиятне рус халык әкияте белән чагыштыру | | | |
| 8 | “Хәйләкәр төлке”, “Солдат балтасы” | Проблемалы дәрес | “Хәйләкәр төлке”, “Солдат балтасы” | Халык авыз иҗаты әсәрләренең | Текстны сәнгатьле укый белү; әсәр | “Хәйләкәр төлке”, “Солдат балтасы” әкиятләре белән | Укыган әкиятләрнең кайсы төркемгә керүен | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | әкиятләре | | әкиятләрен уку, эчтәлегенә төшенү. | тормышта кирәклеген, аларның кешегә тәрбия бирүен аңлау | геройларына характеристика бирә белү; әдәби әсәр теленең үзенчәлекләрен, әсәр сюжетын ачыклый белү | танышу; “туган-тумача”, “туган-үскән җир” төшенчәләренең мәгънәләрен аңлау | ачыклау; төп геройларны, сюжетын, башлам һәм бетем өлешләрен табу; хәйләкәр геройга характеристика бирү | | | |
| 9 | “Камыр батыр” әкияте | Катнаш дәрес | “Камыр батыр” әкиятен уку, эчтәлегенә төшенү | Халык авыз иҗаты әсәрләренең тормышта кирәклеген, аларның кешегә тәрбия бирүен аңлау | Әсәрдән мөһим мәгълүматны аерып ала белү; әсәр геройларына характеристика бирә белү; укытучы һәм сыйныфташлар белән уртак эшчәнлек оештыра белү | “Камыр батыр” әкияте белән танышу, әкият төзелешен өйрәнү | Әкиятне уку; эчтәлеге буенча әңгәмә кору; герой турында сөйләшү; Ф.Ризаева иллюстрациясе буенча эшләү | | | |
| 10 | “Өч каләм” әкияте | Дәрес-практикум | “Өч каләм” әкиятен уку, эчтәлегенә төшенү | Тормышта мөстәкыйльлек, үз көчеңә ышаныч кирәклеген аңлау; халык авыз иҗаты әсәрләренең тормышта кирәклеген, аларның кешегә тәрбия бирүен аңлау | Сүзлек өстендә эшли белү; автор әйтергә теләгән төп фикерне таба белү; композиция, сюжет элементларын, тел-сурәтләү чараларын, әсәр эчтәлеген билгеләүдәге ролен ачыклый белү | “Өч каләм” әкияте белән танышу; “вәзир”, “дию” төшенчәләренең мәгънәләрен аңлау | Әкиятне уку, сюжетын ачыклау; әкиятнең төрен билгеләү; рәсемнәргә карап, дию турында белгәннәрне сөйләү | | | |
| 11 | “Кәтән Иваныч” әкияте (сыйныфтан | Яңа материалны аңлату | “Кәтән Иваныч” әкиятен уку, эчтәлегенә | Урыны белән тормышта хәйләнең дә | Проблеманы аңлый белү; гипотеза чыгару, | “Кәтән Иваныч” әкияте белән танышу; әкият | Әкиятне уку, сюжетын ачыклау; ”Татарларда | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тыш уку) | | төшенү | файдасы барын аңлау; халык авыз иҗаты әсәрләренең тормышта кирәклеген, аларның кешегә тәрбия бирүенә төшенү | үз фикерен раслау өчен дәлилләр сайлый белү; телдән һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып ала, нәтиҗәләрне формалаштыра белү | төрен, сюжет тәртибен билгеләү | отчество бармы?” дигән сорауга җавап эзләү; әкияттә бирелгән рус сүзләрен табу, алар урынына татар сүзләре куеп уку | | | |
| 12 | Б.с.ү. Бишек җырлары | Катнаш дәрес | Халык әкиятләрен гомумиләштере п кабатлау, аларның төрләргә бүленешен искә төшерү, бишек җырлары турында мәгълүмат алу | Гаиләдә туганлык, бер-береңә җылы мөнәсәбәт, ата-анага мәхәббәт хисләре белән карарга кирәклекне аңлау; бишек җырларының кеше тормышында тәрбияви роль уйнавын аңлау | Әдәбиятны музыка белән бәйләп карый белү; халык җырларын автор җырлары белән чагыштырып карый белү; әсәрне укыганда үз алдыңа максат куя белү;укытучы белән бергәләп, үз эшеңне, иптәшләреңнең җавапларын бәяли белү. | Бишек җыры төшенчәсе белән танышу; И.Юзеев, Э.Шәрифуллина, Р.Вәлиев шигырьләре белән танышу | Бишек җырлары турындагы текстны уку; Э.Шәрифуллинаны ң “Бишек җыры”н уку, халык җырлары белән чагыштыру; автор әсәрләрендә балага әйтелгән ягымлы сүзләрне табу | Тест | | |
| **Халык иҗаты белән рухланып** | | | | | | | | | | |
| 13 | Мәсәлләр. Г.Тукай һәм Ә.Исхак мәсәлләре | Яңа материалны аңлату | Г.Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне киңәйтү, мәсәл жанрын карау | Әдәп-әхлак, акыл төшенчәләре нең кеше тормышында гы ролен аңлау | Бер үк темага язылган мәсәлләрне чагыштырып өйрәнә белү; автор әйтергә теләгән төп фикерне таба | Г.Тукай һәм Ә.Исхак мәсәлләре белән танышу; мәсәл төшенчәсен аңлау | Мәсәл текстын укып, фикер алышу; Г.Тукай һәм Ә.Исхак мәсәлләрен укып чагыштыру | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | белү | | | | | |
| 14 | Г.Тукай һәм И.Крылов мәсәлләре | Яңа материалны аңлату | Мәсәл жанрын үзләштерү, Г.Тукай һәм И.Крылов мәсәлләрен уку | Әдәп-әхлак, акыл төшенчәләренең кеше тормышындагы ролен аңлау; эшләнелгән гамәлләрдән чыгып, үзеңә дәрес алу | Мәсәлләрне чагыштырып өйрәнә белү; ике мәсәлнең охшаш һәм аермалы якларын таба белү; мөстәкыйль рәвештә төрле текстларны уку, өстәмә сорауларга җавап бирә белү | Г.Тукай һәм Ә.Исхак мәсәлләре белән танышу; мәсәл төшенчәсен аңлау | Г.Тукай һәм И.Крылов мәсәлләрен уку, аларны чагыштыру; ике мәсәлнең охшаш һәм аермалы якларын табу | | | |
| 15 | Г.Тукай һәм Г.Шамуков мәсәлләре | Катнаш дәрес | Мәсәл жанрын кабатлау, Г.Тукай һәм Г.Шамуков мәсәлләрен уку | Әдәп-әхлак, акыл төшенчәләренең кеше тормышындагы ролен аңлау | Мәсәлләрне чагыштырып өйрәнә белү; автор әйтергә теләгән төп фикерне таба белү, уку гамәлләрен бәяли белү | Г.Тукай һәм Ә.Исхак мәсәлләре белән танышу | Г.Тукай һәм Г.Шамуков мәсәлләрен уку, аларны чагыштыру; ике мәсәлнең охшаш һәм аермалы якларын табу | Тест | | |
| **Хәзинә. Борынгы әдәбиятыбыз үрнәкләре** | | | | | | | | | | |
| 16 | Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәре | Яңа материалны аңлату | Борынгы әдәбиятыбыз үрнәкләрен карау, Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәрен уку | Борынгы хәзинәбез үрнәкләренең әдәбиятта тоткан ролен һәм укучыга тәэсирен аңлау | Татар әдәбиятын рус әдәбияты белән чагыштырып өйрәнә белү; сүзлекләр белән эшли белү; әдәби әсәр теленең үзенчәлекләрен ачыклый белү; үз хезмәтеңне бәяли белү | Кол Галинең тормышы һәм иҗаты турындагы кыскача фактлар белән танышу, “Кыйссаи Йосыф” әсәре белән танышу; борынгы әдәбият үрнәкләре төшенчәсе белән танышу | “Кыйссаи Йосыф” әсәреннән өзек уку; сораулар буенча эчтәлекне ачыклау; әсәрдән әкияти сюжетларны табу | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 17 | Кол Гали. “Кыйссаи Йосыф” әсәре | Яңа материалны аңлату | Борынгы әдәбиятыбыз үрнәкләрен карау, Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәрен өйрәнү | Дуслык, татулык, туганлык хисләрен аңлау; борынгы хәзинәбез үрнәкләренең әдәбиятта тоткан ролен һәм укучыга тәэсирен аңлау | Әдәби әсәрне өйрәнү өчен, тарихи мәгълүматларда н файдалана белү; әдәби әсәрне ишетеп кабул итә белү; укытучы белән бергәләп, үз эшеңне, иптәшләреңнең җавапларын бәяли белү | Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәре белән танышу; борынгы әдәбият үрнәкләре төшенчәсе белән танышу; борынгы сүзләрнең мәгънәләрен аңлау | Борынгы, мәгънәләре аңлашылмаган сүзләрне дәфтәргә язу; өзекне уку; Йосыф турында сүзле картина төзү; Йосыф белән Мәлик төшләре турында сөйләшү | | | |
| 18 | Ш.Галиев. “Кол Галигә” шигыре | Йомгаклау дәресе | Ш.Галиевның “Кол Галигә” шигырен уку, поэма төзелешен тикшерү | Татар әдәбиятының тормышта тоткан ролен һәм кешегә тәэсирен аңлау | Татар әдәбиятына үз мөнәсәбәтеңне формалаштыра белү; әңгәмә кора белү; монологик сөйләмне куллана белү; мәгълүматны төрлечә итеп үзгәртә белү | Кол Гали иҗатына бүгенге көн язучыларының бәясе белән танышу; дастан һәм поэма терминнарын аңлау | Поэма төзелеше белән танышу; “Кол Галигә” шигырен уку; Кол Галигә Ш.Галиев биргән бәяне табып уку; “Кыйссаи Йосыф” әсәренең планын төзү | Тест | | |
| **Казан ханлыгы әдәбияты үрнәкләре** | | | | | | | | | | |
| 19 | Мөхәммәдьяр иҗаты | Яңа белемнәрне ачу дәресе | Казан ханлыгы чоры әдибе Мөхәммәдьяр иҗаты белән таныштыру | Борынгы хәзинәбез үрнәкләренең әдәбиятта тоткан ролен һәм укучыга тәэсирен аңлау; кеше хәленә керә белү, | Укуның төрле формаларыннан файдалана белү; укылган әсәргә анализ ясый белү; укытучы һәм сыйныфташлар белән уртак эшчәнлек | Мөхәммәдьярның тормыш юлы турында кыскача белешмә алу; хикәятне өйрәнү | Шагыйрь Мөхәммәдьяр турында дәреслектә бирелгән текстны уку; хикәятне уку, сораулар буенча эчтәлекне ачу; әсәрдә күтәрелгән проблемаларны | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | юмартлылык хисләренә төшенү | оештыра белү. | | табу | | | |
| **XIX йөз әдәбияты үрнәкләре** | | | | | | | | | | |
| 20 | Каюм Насыйри иҗаты | Яңа белемнәрне ачу дәресе | Укучыларны XIX йөз әдәбияты язучысы Каюм Насыйри иҗаты белән таныштыру; “Патша белән карт”, “Аңгыралык бәласе”, “Бай һәм хезмәтче” әсәрләре укып анализлау | Әдәп-әхлак нормаларының кеше тормышындагы ролен аңлау | Әсәргә анализ ясый белү; геройларга характеристика бирә белү; башкаларны тыңлау, кирәк булганда үз фиереңне үзгәртә белү; үз хезмәтеңне бәяли белү | Каюм Насыйриның тормыш юлы һәм иҗаты белән, “Патша белән карт”, “Бай һәм хезмәтче” әсәрләре белән танышу | Хикәятләрне укып, фикер алышу; падишаһка хас сыйфатларны билгеләү; хезмәтче малайга характеристика бирү | | | |
| 21 | Б.С.Ү. “Эш үткәч, үкенүдән файда юк” темасына сочинение язу | Катнаш дәрес | Мәкальләр уку, сочинение язу | Хезмәтнең кыйммәтен аңлау | Фикерне язма формада бирә алу; диалог төзүдә катнашу, үз фикереңне төгәл һәм тулы итеп әйтә белү | Мәкаль-әйтемнәр белән танышу | Мәкаль-әйтемнәрне уку; хезмәт турындагы әйтемнәрне искә төшерү, сочинение язу | | | |
| 22-23 | К.Насыйри. “Әбүгалисина” әсәре | Яңа белемнәрне ачу дәресе | К.Насыйриның “Әбүгалисина” әсәреннән өзекне укып анализлау | Ихтыяр көченең, белемнең тормышта кирәклеген аңлау | Халык авыз иҗаты турында белү; сүзлекләр белән эшли белү; әсәр эчтәлеген төрле формаларда ача белү | К.Насыйриның “Әбүгалисина” әсәре белән танышу; сүзләрнең мәгънәләрен аңлау. | “Әбүгалисина” әсәрен бүлекләп уку, һәр бүлеккә исем бирү; әсәр эчтәлеге буенча план төзү, сөйләү | | | |
| 24 | Б.С.Ү. Әсәргә миниатюр рецензия язу. Каюм Насыйри музеена сәяхәт | Рефлексия дәресе | Каюм Насыйриның “Әбүгалисина” әсәренә рецензия язу | Ихтыяр көченең, белемнең тормышта кирәклеген аңлау. | Әдәби терминологиянең гади вариантларын куллана белү; актив, | Дәреслектән К.Насыйри музее белән танышу; рецензия төшенчәсен аңлау | Дәреслек битендәге материал белән танышу; рецензия өстендә телдән эшләү; мөстәкыль | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | мөстәкыйль фикер йөртә белү; үз фикереңне дәлилли белү | | рәвештә рецензия язу | | | |
| **XX йөз башы татар әдәбияты үрнәкләре** | | | | | | | | | | |
| 25 | Г.Тукай – татар халкының бөек шагыйре. “Су анасы” әкият-поэмасы | Рефлексия дәресе | XX йөз башы татар әдәбияты үрнәкләре. Татар халкының бөек шагыйре - Г.Тукайның тормыш юлы һәм әсәрләре белән танышу | Татар әдәбиятына, мәдәниятына ихтирамлы мөнәсәбәттә булырга кирәклеген аңлау | Дәреснең темасын, максатын формалаштыру, эшчәнлеккә бәя бирү; автор әйтергә теләгән төп фикерне таба белү; монологик сөйләмне куллана белү; рус әдәбияты белән чагыштырып, мифик образлар сурәтләнгән әсәрләрне анализлый белү | Г.Тукайның тормыш юлы һәм “Су анасы” әкияте белән танышу; әкият-поэма төшенчәсен аңлау; Тукай-Кырлай музей комплексы белән танышу | Дәреслек өстендә эш; иллюстрация буенча сөйләшү; әкият-поэманы уку; Су анасын тасвирлап сөйләү; Тукай турында язучылар фикерен уку | | | |
| 26 | Г.Тукай. “Эш беткәч уйнарга ярый” әсәре (сыйныфтан тыш уку) | Рефлексия дәресе | Ике шагыйрьнең бер үк темага багышлап язылган әсәрләрен чагыштырып өйрәнү | Вакытның кадерен аңлау | Башкалар фикерен тыңлау, үз фикереңне белдерә белү; мөстәкыйль рәвештә дәрес проблемасын формалаштыра белү; әсәргә анализ ясый, сүзлекләр белән эшли белү. | Г.Тукайның “Эш беткәч уйнарга ярый” әсәре, Б.Рәхмәтнең “Эш беткәч” шигыре белән танышу; нәзыйрә жанры төшенчәсен аңлау | Әсәрләрне уку; Б.Рәхмәт шигыренең нәрсә турында икәнен исеме буенча ачыклау; ике әсәрне укып чагыштыру; рифмалашкан сүзләрне табу | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **XX йөз татар әдәбияты үрнәкләре** | | | | | | | | | | |
| 27 | Г.Ибраһимов. “Яз башы” әсәре | Яңа белемнәрне ачу дәресе | Г.Ибраһимовның “Яз башы” әсәрен укып анализлау | Табигатьнең матурлыгын күрә белүне һәм саклый белүне аңлау | Мөстәкыйль рәвештә төрле текстларны укый, сүзлекләр белән эшли белү; әдәбиятны рәсем сәнгате белән бәйләп, матурлыкны таныргa өйрәнү; төрле фикерләрне исәпкә алу һәм үз позицияңне нигезләү | Г.Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты, “Яз башы” әсәре белән танышу | “Яз башы” хикәясен уку; фикер алышу; рәсем ясау | | | |
| 28 | Г.Ибраһимов. “Фагыйлә” хикәясе. Хикәя жанры | Яңа белемнәрне ачу дәресе | Г.Ибраһимовның “Фагыйлә” хикәясе, хикәя жанры белән танышу | Табигатьнең матурлыгын күрә белүне һәм сакчыл караш тудырырга кирәклеген аңлау | Сәнгатьле укый белү; сүзнең эстетик вазифасын, сурәтләү көчен аңлау; әдәбиятны рәсем сәнгате белән бәйләп, иптәшләреңнең эшен бәяләү; үз фикереңне бәяли белү | Г.Ибраһимовның “Фагыйлә” хикәясе белән танышу; хикәя жанры төшенчәсен аңлау | “Фагыйлә” хикәясен уку, тау битендәге җиләклекне тасвирлап сөйләү; кызның бөрлегән ашаганын тасвирлаган урынны табып, сәнгатьле уку. | | | |
| 29-31 | М.Җәлил. “Алтынчәч” либреттосы | Яңа белемнәрне ачу дәресе | “Алтынчәч” либреттосыннан өзекләр уку | Туган илнең матурлыгын аңлау; туган илнең кеше тормышында гы ролен аңлау | Әдәби әсәрне аңлау өчен, чор белән бәйле тарихи мәгълүматларны белү; төрле фикерләрне исәпкә алу һәм | М.Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу; “Алтынчәч” либреттосыннан өзек белән танышу; либретто, ария, | М.Җәлилнең биографиясен уку; Алтынчәч һәи Җик арияләрен уку; поэманың геройлары турында сөйләшү, уңай һәм тискәре | Мөстә-кыйль эш | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | үз позицияңне нигезли белү; бердәм карар кабул итә белү; әсәрне анализлаганда гади әдәби терминология куллана белү; үзеңнең һәм иптәшләреңнең җавапларын бәяли белү | строфа төшенчәләрен аңлау | геройларның төп сыйфатларын табу; рифма төрләрен искә төшерү | | | |
| **Сугыш чоры әдәбияты** | | | | | | | | | | |
| 32 | М.Җәлил. “Кызыл ромашка”, “Җырларым” шигырьләре | Яңа белемнәрне ачу дәресе | Сугыш чоры әдәбиятына күзәтү. Баллада төшенчәсе. М.Җәлилнең “Кызыл ромашка”, “Җырларым” шигырьләре белән танышу | Сугышның тормышыбызны авырайтуын, яшәү кыйммәтләрен юкка чыгаруын аңлау; патриотик хисләрнең көчен аңлау. | Текстларны яттан сөйли белү; әсәргә анализ ясый белү; “Ромашкалар кыры” рәсеме буенча үз фикереңне белдерү һәм башкаларның хезмәтен бәяли белү; төрле фикерләрне исәпкә алып эш итә белү | М.Җәлилнең сугыш чоры иҗаты турында кыскача белешмә алу; “Кызыл ромашка”, “Җырларым” шигырьләрен уку һәм анализлау | “Кызыл ромашка” шигырен уку, “Җырларым” шигырен уку, эчтәлеге буенча әңгәмә; җырның көче турында сөйләшү; дәреслектә бирелгән рәсем буенча эшләү | | | |
| 33 | Б.С.Ү. “Хөкем алдыннан” картинасы буенча сочинение | Катнаш дәрес | Сугыш чоры әдәбиятына күзәтү. Картина өстендә эш | Туган илгә булган хисләрнең, ихтыяр көченең кыйммәтен аңлау | Рәсемгә карап фикер йөртә белү; иптәшләреңнең фикерләрен исәпкә алып эш итү; автор | “Хөкем алдыннан” картинасы белән танышу | “Хөкем алдыннан” картинасы өстендә эшләү, сорауларга җавап бирү, сочинение язу | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | күрсәтергә теләгән төп фикерне таба белү | | | | | |
| 34 | М.Җәлил. “Бүреләр” шигыре | Рефлексия дәресе | М.Җәлилнең “Бүреләр” шигырен уку, эчтәлегенә төшенү | Сугыш кырларында илебезнең азатлыгы өчен кан коелуның мәгънәсен аңлау, җиңү өчен барган авыр көрәшнең кыйммәтен аңлау | Сәнгатьле укый белү; үз эшчәнлегеңне мөстәкыйль оештыра белү; әсәргә анализ ясый, шәрехли белү; үз фикереңне дәлилли белү | М.Җәлилнең “Бүреләр” шигырен уку һәм анализлау | “Бүреләр” шигырен сәнгатьле уку; бүреләрнең ролен аңлау; төркемнәрдә эшләү | | | |
| 35 | М.Җәлил музейларына сәяхәт | Яңа белемнәрне ачу дәресе | Музейлар турында сөйләшү. М.Җәлилнең үлемсез батырлыгы турында сөйләшү | Язучының патриотик шагыйрь, каһарман сугышчы булуын, туган илгә булган мәхәббәтен аңлау | Татар әдәбияты һәм мәдәниятенең рухи кыйммәтләрен якынайта белү; укытучы һәм иптәшләрең белән фикер алыша белү | Дәреслектә М.Җәлил музее белән танышу | Төркемнәрдә эшләү; музейлар турында сөйләү; дәреслектәге материалны уку | | | |
| 36 | Б.С.Ү. “Сугыш узган җирдә” темасына сочинение язу | Катнаш дәрес | Сугыш чоры әдәбиятына күзәтү. Сочинение язу | Сугышның куркыныч афәт икәнен аңлау; сугыш кырларында илебезнең азатлыгы өчен кан коелуның мәгънәсен | Үз фикереңне төгәл итеп әйтеп бирү; иптәшләреңнең фикерен ишетә белү; монологик һәм диалогик сөйләм төзи белү | Бөек Ватан сугышы турындагы материаллар белән танышу, сочинение язу | Кинофильмнар буенча әңгәмә алып бару; Бөек Ватан сугышы турындагы мәгълүматны искә төшерү, сорауларга җавап бирү, сочинение язу | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | аңлау | | | | | | |
| 37 | Р.Мостафин. “Балыкчы Муса” әсәре (сыйныфтан тыш уку) | Катнаш дәрес | Муса Җәлилгә багышланган “Балыкчы Муса” хикәясен уку, эчтәлеген аңлау | Балачакның матур чак икәнен аңлау; табигать матурлыгын күрә белү | Төрле чыганаклардан язучының иҗатын өйрәнә белү; укылган әсәрнең эчтәлеген сөйли белү; төрле фикерләрне исәпкә алып эш итә белү | М.Җәлилнең балалык еллары белән танышу; Р.Мостафинның “Балыкчы Муса” хикәясен уку, анализлау | Хикәяне уку; балык тоту кирәк-яраклары турында сөйләшү; балыкка баргач, үзләре белән булган кызык хәлләрне сөйләү, белемнәрне гомумиләштерү, тест эшләү | Тест | | |
| 38 | Ф.Кәрим. “Кыр казы”, “Ватаным өчен” шигырьләре | Яңа белемнәрне ачу дәресе | Ф.Кәримнең “Кыр казы”, “Ватаным өчен” шигырьләрен укып анализлау | Туган ил азатлыгы өчен башларын салганнарның батырлыгын аңлау | Телдән әңгәмә кора белү; татар әдәбиятының күренекле вәкилләрен белү; сәнгатьле укый белү | Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат алу; “Кыр казы”, “Ватаным өчен” шигырьләрен укып анализлау | Ф.Кәрим әсәрләреннән ясалган күргәзмәне карау; шигырьләрне уку, чагыштыру, уртак һәм аермалы якларны табу | | | |
| 39 | Ф.Кәрим “Гармунчы Аю белән җырчы Маймыл” әсәре | Рефлексия дәрес | Ф.Кәримнең “Гармунчы Аю белән җырчы Маймыл” әсәрен укып өйрәнү | Хайваннан дөньясының кызыклыгын аңлау | Телдән диалог төзи белү; әсәрдән юмор таба белү; фольклор һәм язучы әсәрендәге проблемаларны ачыклый белү; укуның төрле формаларын куллана белү | Ф.Кәримнең “Гармунчы Аю белән җырчы Маймыл” әсәре белән танышу | Әкият төрләрен кабатлау; әсәрне чылбыр рәвешендә уку; әкиятнең халык әкияте белән уртак һәм аермалы якларын табу, иң кызыклы җавапны ачыклау | | | |
| 40 | Г.Кутуй. “Сагыну” нәсере | Яңа белемнәрне ачу дәресе | Г.Кутуйның кыскача тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу, “Сагыну” нәсерен | Кеше тормышында туган илнең зур урын тотуын аңлау | Әдәбиятны география предметы белән бәйләп, дөнья турында | Г.Кутуйның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскач. белешмә алу, “Сагыну” | Дәреслектәге материалларны уку; эчтәлек буенча әңгәмә оештыру; сагыну | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | уку | | күзаллау формалаштыра белү; әсәрнең эчтәлеге буенча әңгәмә кора белү; сагыну турында әңгәмә кору | нәсере белән танышу; нәсер жанрын аңлау | турында сөйләшү; әсәрдәге географик атамаларны табу, картадан күрсәтү | | | |
| 41 | А.Алиш. “Килделәр” хикәясе | Яңа белемнәрне ачу дәресе | А.Алишның тормышы һәм иҗаты турында белешмә бирү, “Килделәр” хикәясен анализлау | Сугыш авырлыклары н, сугыш барган шәһәрдә калган кешеләр хәлен аңлау | Сугыш темасына багышланган башка әсәрләр белән чагыштыру; әсәрнең мәгънәсен аңлап, авторның төп фикерен таба белү; укыганнарны гомумиләштереп , нәтиҗә ясау | А.Алишның тормышы һәм иҗаты белән танышу; “Килделәр” хикәясе белән танышу | “Килделәр” хикәясен уку, эчтәлеген ачыклау; әсәр буенча план төзү; анализлау | | | |
| 42 | С.Хәким. “Колын” шигыре. С.Хәким музеена сәяхәт | Яңа белемнәрне ачу дәресе | Сугыш чоры әдәбиятын кабатлау. С.Хәкимнең “Колын” шигырен уку | Авыр сугыш елларында хайваннарны ң да өлеше керүен аңлау, аларны кызгану хисен кичерү | Кирәкле мәгълүматны төрле формада бирелгән чыганаклардан туплый белү; сәнгатьле укый белү; төрле фикерәрне исәпкә алу һәм үз позициянне нигезли белү | С.Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат алу; “Колын” шигырен укып анализлау | Дәреслектә бирелгән автобиографик текстны уку; “Колын” шигырен уку һәм анализлау; “Сугышта атлар да көрәште” дигән темага сөйләшүдә катнашу; атлар турындагы әсәрләрне искә төшерү | | | |
| 43 | Б.С.Ү. Л.Лерон. “Фашист очып узды” шигыре | Бәйләнешле сөйләм үстерү | Шигырь уку, картина өстендә эшләү | Сугышның куркыныч афәт икәнен | Сәнгатьле укый белү; картинага нигезләнеп, үз | Л.Леронның “Фашист очып узды” шигырен уку | Л.Леронның “Фашист очып узды” шигырен | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | дәресе | | аңлау; ерткычлыкның тормышта иң начар сыйфат икәнен аңлау | фикереңне әйтә белү; билгеле бер күрсәтмә нигезендә эшли белү; әңгәмә кора белү; үз хезмәтеңә бәя бирә белү | һәм анализлау, А.Пластовның "Фашист самолеты очып үтте" картинасы белән танышу | уку; А.Пластовның "Фашист самолеты очып үтте" картинасы өстендә эшләү, сорауларга җавап бирү | | | |
| 44 | Р.Харис. “Ветеран дәфтәрләр” шигыре | Рефлексия дәресе | Сугыш чоры истәлекләрен үзендә саклап, туган иленә әйләнеп кайткан солдат көндәлеге турында Р.Харисның “Ветеран дәфтәрләр” шигырен укып анализлау | Сугыш кырында канын койган солдатларның батырлыгына төшенү | Төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади укый белү; иптәшләрең алдында чыгыш ясый белү; бәхәсләшә, үз фикереңне дәлилли, анализ ясый белү | Р.Харисның “Ветеран дәфтәрләр” шигыре белән танышу; метафора төшенчәсен аңлау | Р.Харисның “Ветеран дәфтәрләр” шигырен уку; “Ветеран дәфтәр” – метафора, метафораның нәрсә икәнлеген кабатлау; тема буенча тест эшләү | Тест | | |
| **Сугыштан соңгы чор әдәбияты** | | | | | | | | | |
| 45-46 | Ф.Хөсни. “Чыбыркы” хикәясе | Яңа белемнәрне ачу дәресе | Ф.Хөсни турында белешмә бирү, “Чыбыркы” хикәясен өйрәнү | Һөнәрне дөрес сайлау, җаныңа якын һөнәрнең генә күңелгә рәхәтлек бирүе турында аңлау | Чыбыркының нинди предмет икәнен аңлап, аңлы рәвештә сөйләшү; текстны кабул итү һәм аның эчтәлегендә ориентлаша белү; һөнәр сайлау турында иптәшләрең белән фикер алыша белү | Ф.Хөснинең тормышы һәм иҗаты турында белешмә алу, “Чыбыркы” хикәясен уку һәм анализлау | “Чыбыркы” хикәясен чылбыр рәвешендә уку; дәреслектәге сорауларга җавап бирү; “Рәшит нинди малай?” соравына җавап язу | | | |
| 47 | Роберт Әхмәтҗанов. | Яңа белемнәрне | Сугыш чоры әдәбиятын | Солдатлар белән | Иптәшләреңнең эшенә бәя бирә | Роб.Әхмәтҗановның тормышы һәм | Солдат тормышы турында сөйләшү; | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | "Солдатлар" шигыре | ачу дәресе | кабатлау, “Солдатлар” шигырен уку | горурлану; солдат тормышының авырлыкларын аңлау | белү; әдәбиятны география предметы белән бәйләп, кешелек җәмгыяте турында күзаллау формалаштыра белү; әдәбиятны музыка белән бәйләп, сүз сәнгатенең кыйммәтенә төшенә белү | иҗаты турында белешмә алу, “Солдатлар” шигырен укып анализлау | шигырьне сәнгатьле итеп уку; текст ахырындагы сорауларга җавап бирү; Идел һәм Дунай елгалары турында искә төшерү; җыр тыңлау | | | |
| 48 | Н.Дәүли. “Бәхет кайда була?” шигыре | Яңа белемнәрне ачу дәресе | Н.Дәүлинең иҗаты турында мәгълүмат бирү, “Бәхет кайда була?” шигырен өйрәнү, бәхет турында сөйләшү | Хезмәтнең кеше тормышында гы ролен аңлау | Проблеманы аңлый белү, үз фикереңне раслау өчен, дәлилләр сайларга өйрәнү; бер фикер кабул иткәнче, төрле җавапларны тыңлый, чагыштыра, нәтиҗә ясый белү | Н.Дәүлинең тормышы һәм иҗаты турында белешмә бирү, “Бәхет кайда була?” шигыре уку һәм анализлау | Дәреслектән биографик белешмәне уку; проблемалы сорауга җавап эзләү; бәхет, хезмәт турында мәкальләрне укып, мәгънәләрен аңлау; төркемнәрдә эшләү | | | |
| 49 | Н.Дәүли. “Кар нинди җылы” хикәясе | Яңа белемнәрне ачу дәресе | Гаилә турында сөйләшү, Н.Дәүлинең “Кар нинди җылы” хикәясен өйрәнү | Гаилә ныклыгын саклап калуда баланың ролен аңлау | Төрле фикерләрне исәпкә алып эш итә белү; деликатлылык сыйфатларын булдыра белү; бәхәсләшү, үз фикереңне дәлилләү | Н.Дәүлинең “Кар нинди җылы” хикәясе уку һәм анализлау | Малайларның үз әтиләре турында нәрсә уйлауларын дәреслектән табып уку; Гариф һәм Илгизне характерлый торган сыйфатлар уйлау | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 50 | Ф.Яруллин. “Зәңгәр күлдә Ай коена” хикәясе | Яңа белемнәрне ачу дәресе | Ф.Яруллинның “Зәңгәр күлдә Ай коена” хикәясен уку | Бер-береңә булышу, файда китерүнең яхшы гамәлләр икәнен аңлау | Төрле мәгълүмат чаралары белән эш итә белү; әдәби әсәр теленең үзенчәлекләрен ачыклый белү; укытучы белән бергәләп, үзеңнең һәм иптәшләреңнең җавапларын бәяләү | Ф.Яруллинның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат алу; “Зәңгәр күлдә Ай коена” хикәясе белән танышу; автор әкияте төшенчәсен аңлау | Текст өстендә эшләү; “Ай” дип башланып киткән кыз һәм малай исемнәре язу; бу әкиятнең халык әкиятеннән аермасын табу; әсәрдән сурәтләү чараларын табу | | | |
| 51 | Кеше кайчан бәхетле була? | Рефлексия дәресе | Р.Вәлиеваның "Бәхет", Ф.Яруллинның ”Бөтенесе кирәк” шигырьләрен уку | Бәхетле булуның үзеңнән торуын аңлау | Мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын һәм максатларын формалаштыра белү; укылган, тыңланган әсәрләр буенча сорауларга җавап бирә белү; әсәрләрне чагыштырып, анализ ясый белү | Р.Вәлиеваның "Бәхет", Ф.Яруллинның ”Бөтенесе кирәк" шигырьләрен өйрәнү | Шигырьләрне уку; темаларын билгеләү; строфалардагы аралаш рифмаларны язып алу; тема буенча тест эшләү | Тест | | |
| **Туган ил, туган як турында** | | | | | | | | | | |
| 52 | Н.Исәнбәт. “Туган ил” шигыре | Рефлексия дәресе | Туган ил турында сөйләшү. Н.Исәнбәтнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, Н.Исәнбәтнең “Туган ил” | Туган якка мәхәббәт, аның белән горурлану хисләре тәрбияли алу. | Әдәби әсәр авторы турында төрле чыганаклардан мәгълүмат туплый белү; әдәбиятны музыка сәнгате | Н.Исәнбәтнең тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат алу; “Туган ил” шигыре белән танышу; дәреслектә бирелгән | Исәнбәт укыган мәдрәсә исемнәрен уку һәм елларын язу; строфалардан туган җирне ярату турында эзләү; картиналар белән эшләү | Проект яклау | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шигырен уку. | | белән бәйләп, матурлыкны танырга өйрәнү; картиналар буенча үз фикереңне белдерә белү; монологик һәм диалогик сөйләм үстерә белү | картиналар белән танышу | | | | |
| 53 | Э.Шәрифуллина һәм Г.Зәйнашеваның туган якка багышланган шигырьләре | Яңа белемнәрне ачу дәресе | Э.Шәрифуллина һәм Г.Зәйнәшеваның шигырьләрен укып анализлау | Туган җиребезнең матурлыгын күреп, иң кадерле җир икәнен аңлау | Тыңлаган әсәрләр буенча сораулар бирә белү; татар әдәбиятын рус әдәбияты белән бәйләп, уртак проблемаларны үзләштерә белү; фикер агышлары төрле булганда, бер фикергә килә белү | Э.Шәрифуллина һәм Г.Зәйнәшеваларның шигырьләре белән танышу; туган як төшенчәсен аңлау | Туган ил турындагы шигырьләрне уку, чагыштыру; строфалар тәртибен ачыклау, кабатланып килгән юлларны табу, дәреслектә бирелгән биремнәр белән эшләү | | | |
| 54 | Н.Мадьяров. “Сиңа кайттым, гүзәл туган җирем” шигыре | Рефлексия дәресе | Туган ил турында сөйләшү. Н.Мадьяровның “Сиңа кайттым, гүзәл туган җирем” шигырен укып анализлау | Туган җиребезнең матурлыгын күрә белергә өйрәнү | Сәнгатьле укый белү; тел-сурәтләү чаралары таба белү; әдәбиятны рәсем сәнгате белән бәйләп, матурлыкны таный белү; үз хезмәтеңне бәяли белү | Н.Мадьяровның тормыш юлы турында мәгълүмат алу; “Сиңа кайттым, гүзәл туган җирем” шигыре, И.Шишкинның “Яңгыр алдыннан” картинасы белән танышу | Авторның биографиясен уку һәм нинди һөнәр кешеләре булып эшләвен ачыклау; шигырьдән кабатланып килгән юлларны, эндәшләрне табу; риторик эндәшне ачыклау | | | |
| 55 | С.Хәким. “Бер горурлык хисе”, “Башка берни | Рефлексия дәресе | С.Хәким иҗатын өйрәнү, “Бер горурлык хисе”, | Туган җиребез белән | Мөстәкыйль фикер йөртә белү; төрле | С.Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗаты турында | Текстны сәнгатьле уку, шигырь ахырындагы | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | дә кирәкми” шигырьләре | | “Башка берни дә кирәкми” шигырьләрен анализлау | горурлана алу; әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен аңлау | фикерләрне исәпкә алу һәм үз позицияңне нигезли белү; иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү | белешмә алу, “Бер горурлык хисе”, “Башка берни дә кирәкми” шигырьләрен анализлау, лирик герой, строфа төшенчәләрен аңлау | сорауларга җавап бирү; элекке һәм хәзерге Татарстан турында чагыштырып сөйләү | | | |
| 56 | Ф.Садриев. “Тургай ни дип җырлый?” әсәре | Яңа белемнәрне ачу дәресе | Ф.Садриевның “Тургай ни дип җырлый?” әсәрен өйрәнү | Күчмә кошларны сакларга кирәклеген, аларның кеше тормышында гы ролен аңлау | Бәхәсләшә, әдәбиятны экология предметы белән бәйләп, табигать турында күзаллау формалаштыра белү; укылган әсәр буенча сораулар бирә белү | Ф.Садриевның “Тургай ни дип җырлый?” әсәре укып анализлау | Әсәр белән картина өстендә эшләү; уртаклыкларны табу | | | |
| 57 | Р.Вәлиева. “Табигать баласына” шигыре | Үстерелешл е эзләнү дәресе | Р.Вәлиева иҗаты турында белешмә бирү. “Табигать баласына” шигыре өйрәнү. Табигать матурлыгы турында сөйләшү | Табигатьне саклау, аның кеше тормышында гы ролен аңлау | Укытучы сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү; дәреснең темасын, максатын формалаштыра белү | Р.Вәлиеваның тормышы, иҗаты турында кыскача белешмә алу; “Табигать баласына” шигырен анализлау | Китап күргәзмәсен карау; шигырьне укып, ритм, рифмасын табу; кызыл китапка кертелгән үсемлекләр турында сөйләшү | Иҗади эш яклау. | | |
| 58 | М.Әгъләмов. “Матурлык минем белән” шигыре | Үстерелешл е эзләнү дәресе | М.Әгъләмовның “Матурлык минем белән” шигырен укып анализлау | Матурлыкны ң һәрчак янәшәдә булуын, аны күрә белергә, саклый белергә | Үзеңә кирәкле мәгълүматны төрле чыганаклардан туплый белү; сәнгатьле укый белү | М.Әгъләмовның тормышы, иҗаты турында кыскача белешмә алу; “Матурлык минем белән” шигырен укып анализлау | Шигырьне строфа-лап уку, кабатланып килгән юлларны тикшерү; мини-сочинение язу | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | кирәклеген аңлау, сүз сәнгатенең кыйммәтен күрә белү | | | | | | |
| 59 | Туган як турында – шагыйрьләр | Рефлексия дәресе | Туган як турында шигырьләр уку | Туган якның матурлыгын тоя, аңлый белү; туган җиребезнең иң кадерле җир икәнен аңлау | Максатка ирешү юлларын билгели белү; иптәшләрең алдында төрле темаларга чыгыш ясый белү; укылган, тыңланган әсәрләр буенча сораулар, аларга җаваплар бирә белү | Г.Афзал, Р.Вәлиевның шигырьләре белән танышу | Шигырьләрне укып анализлау; текст ахырындагы биремнәрне үтәү; тема буенча өйрәнгән шигырьләрне кабатлау, исемнәрен, авторларын язып алу | | | |
| 60 | Б.С.Ү. Шишкин наратлары | Рефлексия дәресе | Туган як турында шигырьләр уку, картина белән эшләү | Туган якның матурлыгын тоя, аңлый белү; туган җиребезнең иң кадерле җир икәнен аңлау | Үзләштерелгән һәм ныгытырга кирәк булган материалны билгели белү; диалогик һәм монологик сөйләм төзи белү; үзбәя | К.Сибгатуллинның “Шишкин наратлары” шигыре, И.Шишкинның “Нарат урманы” картинасы белән танышу | Шигырь һәм картина өстендә эшләү; тест эшләү | Тест | | |
| **Тәрҗемә әсәрләр** | | | | | | | | | | |
| 61 | А.Платонов. “Ягъфәр бабай” әсәре | Яңа белемнәр ачу дәресе | Тәрҗемә әсәрләрне уку. А.Платоновның “Ягъфәр бабай” әсәрен өйрәнү | Сугыш вакытында тылдагы авыр хезмәт, җимереклекләр, эшләргә кеше юклыктан җыелмаган | Өстәмә белем чыганакларыннан язучының тормышын һәм иҗатын белү; геройларны тасвирлап сөйли белү; диалогик сөйләм төзи белү | А.Платоновның “Ягъфәр бабай” хикәясенең тәрҗемәсе белән танышу | Дәреслектән автор турындагы юлларны уку; әсәрне уку; сүзлек белән эшләү; план төзү, эчтәлек сөйләү | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | иген кырлары, өлкәннәр тормышы авырлыклары н аңлау, хөрмәт хисе булдыру | | | | | | |
| 62 | Дж.Родари. “Әбинең кошчыклары” хикәясе | Яңа белемнәр ачу дәресе | Тәрҗемә әсәрләрне уку. Дж.Родариның “Әбинең кошчыклары” хикәясе белән танышу | Өлкәннәр кадерен, гаилә кыйммәтен аңлау | Әсәр буенча сораулар төзи белү; сүзлек белән эшли белү; укыганны гомумиләштереп , нәтиҗә ясый белү | Дж.Родариның “Әбинең кошчыклары” хикәясен укып анализлау | Текстны уку, дәреслектә бирелгән сораулар буенча эшләү | | | |
| 63 | А.Экзюпери. “Нәни принц” әсәре (сыйныфтан тыш уку) | Яңа белемнәр ачу дәресе | Тәрҗемә әсәрләрне уку. А.Экзюпериның “Нәни принц” әсәре белән танышу | Тормышта хыяллана белүнең, белемнең кирәклеген аңлау | Сүзлек белән эшли белү; бирелгән темага әңгәмә кора белү; мөстәкыйль рәвештә дәреснең максатларын формалаштыра белү | А.Экзюпериның “Нәни принц” әсәрен өйрәнү | Әсәр өстендә эшләү, мөстәкыйль эш эшләү | Мөстә-кыйль эш | | |
| **Шагыйрь һәм язучылар иҗатында юмор** | | | | | | | | | | |
| 64-65 | А.Гыймадиев хикәяләре | Гомуммето-дологик юнәлешле дәрес | А.Гыймадиев әсәрләрендә юморның бирелешен күзәтү | Тормышта юмор белән яшәү җиңелрәк, кызыклырак икәнлегенә төшенү | Диалог төзи, әңгәмә кора белү; кирәкле мәгълүматны табып, анализлый белү; төрле фикерләрне исәпкә алу һәм | А.Гыймадиев хикәяләре белән танышу; юмор төшенчәсен аңлау | Хикәяләрне уку; интернет-сүзлек белән эшләү; хикәяләрдә юморны табу | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | үз позицияңне нигезли белү | | | | | |
| 66 | Шәүкәт Галиев шигырьләре | Гомуммето-дологик юнәлешле дәрес | Шәүкәт Галиев шигырьләрен уку, юмор поэтикасын аңлау | Хезмәтнең кирәклеген, тормыштагы ролен аңлау | Тыңлаган әсәрләр буенча сораулар бирә белү; үз фикереңне кыскача әйтеп бирә белү; белешмә материаллар белән эшли белү | Шәүкәт Галиев шигырьләрен укып анализлау | Шигырьләрне уку, юмор бирелгән урыннарны табып уку, фикер алышу; “Татар исемнәре ни сөйли?” китабыннан “гәүһәр” сүзенең мәгънәсен эзләп табу | | | |
| 67-68 | Л.Лерон. “Зөһрә кыз – безнең авылдан” хикәясе, “Песи булсаң иде” шигыре | Рефлексия дәресе | Л.Лерон иҗатында юморның бирелешен карау, пародия турында сөйләшү | Тормышта хыяллана белүнең, юморның кирәклеген аңлау | Күмәк эш вакытында, фикер агышлары төрле булганда, бер фикергә килә белү; үз фикерен текстан өземтәләр китереп дәлилли белү; шигъри кабатлап сөйләүнең төрле төрләрен куллана белү; әкият һәм чынбарлык элементларын табып, чагыштыра белү | Л.Леронның “Зөһрә кыз – безнең авылдан” хикәясен, “Песи булсаң иде” шигырен укып анализлау; эпиграф төшенчәсен аңлау | Әсәрләрне уку, әкият һәм чынбарлык элементларын табу; гиперболаларны эзләү; юмор элементларын табу; эпиграф төшенчәсен аңлату | | | |
| 69 | Р.Миңнуллин, Р.Корбан иҗатларында юмор | Рефлексия дәресе | Р.Миңнуллин, Р.Корбан иҗатларында юмор бирелешен карау | Тормышта хыяллана белүнең, юморның кирәклеген аңлау | Мөстәкыйль фикер йөртә белү; сүзлек белән эшли алу; мөстәкыйль рәвештә | Р.Миңнуллин, Р.Корбан иҗатлары белән танышу; юмор төшенчәсен аңлау | Шигырьләрне уку, иң оста укучыны билгеләү; сораулар өстендә эшләү | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | дәреснең проблемасын формалаштыра белү; шигъри кабатлап сөйләүнең төрле төрләрен куллана белү | | | | | |
| 70 | Ел буе үткәннәрне йомгаклау. Ф.Яруллин. “Җыр калдырыйк” шигыре | Кабатлау-йомгаклау дәресе | Ел буе өйрәнгәннәрне кабатлау. Ф.Яруллинның “Җыр калдырыйк” шигырен уку | Татар әдәбиятының укучы тормышында гы ролен, яшәешне бизәвен аңлау | Иптәшләреңнең җавапларын бәяли белү; максатка ирешү юлларын билгели белү; активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә, акыл эшчәнлегенә өйрәнә белү | Ф.Яруллинның “Җыр калдырыйк” шигырен өйрәнү | Укучылар үзләре иҗат иткән әсәрләрне уку; Ф.Яруллинның “Җыр калдырыйк” шигырен уку; тест эшләү | Тест | | |

**Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре**
**(V сыйныф) өчен татар әдәбиятыннан эш программасы**

(Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). 5 нче с-ф. Ике кисәктә. / Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Л.К.Хисмәтова. – Казан: "Мәгариф-Вакыт" нәшр., 2014. – 111 б. дәреслеге буенча).

Төзүче-авторлары:

Салихҗанова И.Л., Казан шәһәре Совет районы аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 141 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

Рахимова М.С., Казан шәһәре Совет районы аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 141 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

## Аңлатма язуы

5 нче сыйныфлар өчен татар әдәбиятыннан эш программасы Россия Федерациясендәге һәм Татарстан Республикасындагы мәгарифкә кагылышлы хокукый-норматив актларга һәм федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелде:

1. Россия Федерациясенең “Мәгариф турында”гы Законы (Федеральный закон от 29.12.2012 273-ФЗ “Об образовании в Российской Федерации”).
2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы (Закон Республики Татарстан “Об образовании” № 68-ЗРТ от 22 июля 2013 года, статья 8).
3. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясе халыктелләре турында”гы 126-ФЗ нчы номерлы Законы (24.07.1998).
4. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы приказы, 30 нчы август, 2013 нче ел №115 (“Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – начального общего, основного общего и среднего общего образования”).
5. “Татарстан Республикасының халык телләре турында” Законы (Закон Республики Татарстан от 08.07.1992 № 1560-XII (ред. от 03.03.2012г.) “О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан”).
6. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы, 2004 нче ел, 1нче июль.
7. “2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы”, 2013 нче ел, 25 нче октябрь, 794 нче карар.
8. Төп гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандарты (Россия Мәгариф һәм Фән министрлыгында 2010 нчы елның 17 нче декабрь боерыгы 1897 нче номер белән расланган, РФ Юстиция Министрлыгында 19644 нче регистрацион номеры белән 2011нче елның 1 нче февралендә теркәлгән).
9. Татарстан Республикасында 2012-2020 нче елларда фән һәм мәгариф үсеше турында “Дәүләт программасы”.

1. 2010-2015 нче елларда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү стратегиясе “Киләчәк” программасы.

Эш программасы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән “Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре (V-VII сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан авторлык программасы” (Төзүче-авторлары: А.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Л.К.Хисмәтова, Э.Х.Гыйзәтуллина, Г.Г.Мулласалихова). – Казан, 2014), 5 нче сыйныф өчен Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Л.К.Хисмәтова эшләгән (Казан: "Мәгариф-Вакыт" нәшр., 2014) Татарстанның Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслеккә нигезләнеп төзелде.

Дәреслек: Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). 5 нче с-ф. Ике кисәктә. / Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Л.К.Хисмәтова. – Казан: "Мәгариф-Вакыт" нәшр., 2014. – 111 б.

Рус телле балалар өчен әдәбият укытуның төп **максаты**:

1. Туган халкыбызның һәм җирле халыкның телен, мәдәниятен, әдәбиятын яхшы белгән, һәрьяктан камил шәхес (гражданин) тәрбияләү.

2. Халык тарихын һәм мирасын өйрәнү аша укучыларда Ватанга мәхәббәт, олыларга, кечеләргә һәм гомумән кешегә ихтирам, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек хисләре уяту.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен, түбәндәге **бурычлар** билгеләнде

- Укучының татар әдәби телен үзләштерүенә, текстны аңлап, сәнгатьле итеп, йөгерек укуына, матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку күнекмәләре формалаштыру, телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерү.
- Татар әдәбияты турындагы мәгълүматларны төрле халык фольклоры, әдәбияты, мәдәнияте, милли образлары белән чагыштырма-типологик аспектта бирү;
- Татар халык авыз иҗаты турында тулы күзаллау булдыру, аны баланың үз туган халыкының рухи җәүһәрләре белән чагыштырырга күнектерү;
- Татар әдипләре, мәдәният әһелләре турында күзаллау булдыру, аларны танырга, аңларга, башка халык сүз сәнгатен үстерүчеләр белән чагыштырма планда бәяләргә өйрәтү;
- Балаларны, гомумән, татар әдәбияты, халык авыз иҗаты, татар халкының җыр-музыкасы, сынлы сәнгате белән таныштыру, күренекле язучылар һәм аларның әсәрләрен үзләштерүләренә ирешү, матур әдәбият әсәрләрен (яки әдәби әсәрләрдән өзекне) укып үзләштерү, алар турында үз фикерләрен әйтергә өйрәтү.
- Әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлату һәм кулланырга өйрәтү.
- Укучыларга татар халкының килеп чыгышы, тарихи язмышы, милләттәшләребез тормышы турында мәгълүмат бирү.
- Эстетик тәрбия бирү, табигатькә сакчыл, мәрхәмәтле караш уяту.
- Әдәби әсәрләрне өйрәнү барышында укучыларны сәнгатьле уку алымнарына өйрәтү. Бу җәһәттән эш түбәндәге юнәлешләрдә алып барыла:
  - татар теленең үзенчәлекле авазларын әйтү күнекмәләре булдыру;
  - сүз басымын дөрес куя белү;
  - логик басымны дөрес куя белү;
  - тавышны дөрес төшерә һәм күтәрә белү, ягъни интонацияне дөрес куллану күнекмәләре булдыру һ.б.
- Татар, рус, Россиядә яшәүче башка халыклар, бөтендөнья әдәбияты белеме казанышларының уртак нигезен аңлау, аларны үстерү һәм киңәйтү.

## Уку фәненең уку планында тоткан урыны

Мәктәптә әдәбият предметы – кирәкле, әһәмиятле предметларның берсе. Ул укучыларны тормышны үзенчәлекле итеп танып белергә өйрәтә, хисси-эмоциональ дөньясын баета, эстетик зәвык тәрбияли, сөйләмен үстерә, гомумән, шәхес итеп тәрбияләүдә зур роль уйный.

Укыту планында каралганча, татар әдәбияты дәресләре өчен атнага 2 сәгать исәбеннән елга 70 (35) сәгать бирелә.

## 5 нче сыйныф укучыларының әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:

- әдәби әсәрләрне сүзләрен дөрес әйтеп йөгерек уку;
- авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, үз мөнәсәбәтен белдерү, өлешләргә бүлә һәм планын төзи белү;
- әдәби − теоретик төшенчәләрне рус әдәбияты белеме белән тәңгәлләштерү;
- татар әдәбиятының дөнья культурасында тоткан урынын аңлау;
- авторларның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача күзаллау;
- 8−10 татар, рус, чит ил язучысы, шагыйрьләре исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү;
- 3−4 сәнгать әһеленең тормышы, иҗатын турында мәгълүматлы булу;
- Казан һәм Татарстан төбәгендәге мәдәният учаклары (музей, театр, концерт залы, һ. б.), балалар матбугаты турында белү;
- төрле халыкларның фольклор үрнәкләрен татар халык авыз иҗаты белән чагыштыру;
- төрле халыкларның киң таралган мифларыннан хәбәрдар булу, берничә мисал китерә белү;
- 5 мәкаль, 5 әйтемне русча эквивалентлары белән истә калдыру;
- мәкаль белән әйтем, миф белән әкият, халык җыры белән автор җыры арасындагы аерманы белү;
- төрле авторларның 2−3 шигырен яттан сөйли белү;
- сүзлекләр, энциклопедияләр, Интернет-ресурслардан файдаланып, үзенә кирәкле материалны табу;
- төрле темаларга проект эше яклау;
- әдәби әсәрне тормыш белән бәйләп, үз гамәлләренә бәя бирү.

## Укытуның көтелгән нәтиҗәләре

- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлау;
- классик әдипләрнең (К.Насыйри, Г.Тукай, М.Җәлил, Г. Исхакый) биографик белешмәләре белән танышу;
- өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истә калдыру;
- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү;
- әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
- укыган әсәрнең темасын, проблемасын билгеләү;
- геройларга характеристика бирү;
- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;

- укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңе белдерү;
- әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
- кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
- өйрәнелгән әсәрләргә бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү;
- укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерне дәлилли белү;
- аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, интернет чаралары һ.б. аша эзләү.

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

- туган илгә мәхәббәт, ватанпәрвәрлек хисләре, туган телгә сакчыл караш тәрбияләү;
- милли үзаң формалаштыру;
- укуга карата теләк-омтылыш, җаваплы караш булдыру;
- әйләнә-тирә табигатькә дөрес караш булдыру;
- кешеләр белән аралаша белү культурасы тәрбияләү;
- гаделлек, дөреслек, яхшылык, мәрхәмәтлелек һәм аларның киресе булган сыйфатларны тану, бәяләү;
- алган белем һәм осталыкны тормышта максатчан кулланырга өйрәнү.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

“Әдәбият” курсын өйрәнүнең метапредмет нәтиҗәләре булып, универсаль уку-укыту гамәлләре формалаштыру санала (УУГ)

**Танып-белү гамәлләре:**

- әдәби әсәрне дөрес аңлап уку һәм анализлау;
- дөрес нәтиҗәләр чыгару, гомумиләштерү;
- сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булдыру;
- үз фикереңне исбатлый һәм яклый алырга күнектерү;
- әсәр хакында дөрес фикер йөртә алу.

**Коммуникатив гамәлләр:**

- иптәшеңне тыңлый, ишетә белү, ишеткәнен үз фикере белән чагыштыру;
- нәтиҗәгә килгәнче, төрле карашларны өйрәнү һәм дөрес юлны сайлау;
- үз фикереңне телдән һәм язма формада башкаларга җиткерә белү;
- килеп чыккан проблемаларны уртага салып хәл итү;
- төркемнәргә берләшү, бер фикергә килә белү;
- өлкәннәр һәм яшьтәшләрең белән продуктив уртак гамәл оештыру;
- текст буенча сораулар бирә белү.

**Регулятив гамәлләр:**

- дәреснең темасын, проблемасын, максатын мөстәкыйль таба белү;
- укыту проблемасын чишү;
- план буенча эшли белү;
- үз фикерләреңне мөстәкыйль дәлилләү;
- үзанализ һәм үзбәя булдыру.

**Предмет нәтиҗәләр:**

- төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади уку;

- әдәби әсәрләрне анализлау, аларның билгеле бер жанрга каравын, теманы аңлау һәм формалаштыру, идеясен аңлау;
- геройларга характеристика бирү, төрле әсәрдәге бер яки берничә герой белән чагыштыра белү;
- татар әдәбияты һәм мәдәниятенең әхлакый һәм рухи кыйммәтләрен үзара якынайту, башка халыкларныкы белән чагыштыру;
- төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне ишетеп кабул итү, аңлаешлы уку, эчтәлекне дөрес аңлау.

## Курс темаларының эчтәлеге

**Кереш.**

Язучылар китапның кеше тормышындагы роле турында. Китап бер буынның икенчесенә васыяте. Китапның төзелеше (тышы, титул, форзац битләре, астөшермәләр, бүлек исемнәре); китапны төзүчеләр (авторлары, рәссамы, редакторлары, корректоры, җыючылары, нәшрияты). Татар әдәбияты дәреслеге һәм аның белән эшләү үзенчәлекләре.

**I. Борын-борын заманда.**

**Халык авыз иҗаты.**

Фольклор – халыкның коллектив иҗат җимеше. Анда халыкның теләк-омтылышының чагылышы. Фольклорның вариантлы булуы. Фольклор әсәрләрен башкаручылар (әкият сөйләүчеләр, чичәннәр һ.б.). Фольклор әсәрләренең төрләре, жанрлары. Балалар фольклоры (бишек җырлары, табышмаклар, тизәйткечләр һ.б.).

*Әдәбият теориясе. Фольклор. Халык авыз иҗаты.*

**Татар халык әкиятләре.** Халык прозасының бер төре буларак әкиятләр. Әкиятләрнең хайваннар турында, тылсымлы, тормыш-көнкүреш төрләре булуы. Әкиятләргә салынган мәгънә, аларның әкият төзәтүгә юнәлдерелгән булуы, фәлсәфәсе.

**«Ак бүре» (татар халык әкияте).** Әкияттә яхшылык белән явызлык көрәше. Әкияттә халык морале, тылсым элементлары. Ак бүренең төрки халыкларның тотемы булуы. Әкияттәге традицион образлар. Тылсымлы әкиятләрнең поэтикасы. Тылсымлы әкияттә фантастика.

**Татар халык әкияте «Абзар ясаучы төлке», «Өч кыз», «Башмак», «Куркак юлдаш», рус халык әкиятләре «Төлке белән Алёнушка», башкорт халык әкияте «Карга ни өчен исемен әйтеп бетерми?»** Төрле халык әкиятләрендәге уртак һәм аермалы яклар. Әкиятләрдә халыкның яшәү рәвеше, менталитеты чагылышы. Әкият геройлары, аларга хас сыйфатлар.

*Әдәбият теориясе. Әкият. Әкият төрләре. Әкиятләрнең теле. Гипербола, литота. Әкият формулалары. Чагыштыру.*

**II. Әкият яздым, укыгыз...**

Халык әкиятләреннән үсеп чыккан автор әкиятләре турында мәгълүмат. Аларның уртак һәм аермалы яклары. Автор әкиятләрендә халык әкиятләренең мотивлары, образларының үстерелеше.

**Каюм Насыйри.** Тормыш юлы турында мәгълүмат.

**«Патша белән карт»** әкияте. Әкияттә ил белән идарә итүче образы. Халыкның бер вәкиле булган тапкыр карт образы, аның зирәклеге. Әкиятнең диалогка корылган булуы. **«Күләгә»** әкиятенә салынган мораль.

**Габдулла Тукай.** Әдип турында мәгълүмат.

**«Су анасы» экият-поэмасы.** Әкият-поэмада кеше һәм табигать мөнәсәбәтләре. Су анасы мифик образы. Әсәрдә малай образының бирелеше, аңа салынган мәгънә. Г.Тукай экиятләренә иллюстрацияләр авторы – Байназар Әлменов. Аның иҗаты, ачыш-табышлары.

*Әдәбият теориясе. Әкият-поэма төшенчәсе.*

**Фәнис Яруллинның «Хәтерсез Күке» әкияте.** Әкиятнең эчтәлеге. Күке образы. Авторның ачышы. Халык әкиятләре уртак яклары.

**Владимир Дальның «Кар кызы» әкияте.** Рус халык әкиятынең эчтәлеге. «Төлке белән Алёнушка» әкияте белән уртак яклары.

**Ганс Христиан Андерсенның «Борчак өстендәге принцесса» әкияте.** Әкиятләрдә төрле катлам халык вәкилләрен ачу үзенчәлеге. Әкияттә халык әкиятләренә хас үзенчәлекләр.

**Туфан Миңнуллинның «Гафият турында әкият» әкият-пьесасы.** Драматургиядә халык әкиятләренең мотивын куллану. Гафият исемле малай, әкиятче, мифик образлар, урман җәнлекләре образлары. Алар аша автор идеясенең ачылуы.

*Әдәбият теориясе. Әкият-пьеса төшенчәсе.*

**«Әкият» курчак театры турында мәгълүмат.** Театрлар тарихында курчак театрларының урыны, әһәмияте. Казандагы «Әкият» курчак театрының бинасы, репертуары, җитәкчелеге, режиссёрлары, актёрлары.

**III. Хыял канатларында.**

**Адлер Тимергалин** Адлер Тимергалин турында белешмә.

**«Сәер планетада».** Әсәрдәге вакыйгалар аша балаларда җаваплылык хисләре тәрбияләү. Әсәрдәге фантастик алымнар.

*Теоретик төшенчә. Фантастика. Фантастик элементлар.*

**Рудольф Эрих Распе.**

**«Сигез аяклы куян».** Барон Мюнхгаузен мажараларының берсен өйрәнү. Әсәрдәге чынбарлык белән фантастиканың нисбәте.

**IV. Белем баскычлары.**

**Белемгә омтылу. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе** турында мәгълүмат. Мәдрәсәнең 1882 нче елда Казанда ачылуы. Анда белем алучыларның шәкертләр дип аталуы.

**Казанның Татар укытучылар мәктәбе** турында мәгълүмат. Аның 1876 нчы елда ачылуы. Дүрт ел дәвамында белем алган укучыларның рус теле укытучысы булып китүе. Аларны Василй Радлов, Василий Богородицкий, Каюм Насыйри укытуы.

**Казан университеты** турында мәгълүмат. Аның 1804 нче елның 17 нче ноябрендә ачылуы. Анда Карл Фукс, Илья Березин, Николай Лобачевский эшләве. Анда белем алган атаклы кешеләр. Хәзер аның Казан (Идел буе) федераль университеты дип аталуы.

**Гаяз Исхакый.** Язучы турында мәгълүмат.

**«Мөгаллим» пьесасы**. Салих образы. Аңа салынган автор идеалы.

**Дәрдемәнд.** Дәрдемәнд турында мәгълүмат.

**«Кил, өйрән...» шигыре.** «Кил, өйрән...» шигыренә бәйләп телләр белүнең әһәмияте турында сөйләшү.

**V. Балачак – хәтерләрдә мәңге калачак...**

**Габдулла Тукайның «Исемдә калганнар» әсәреннән өзек**. Әсәрдә кечкенә Тукай образының бирелүе. Автобиографик әсәр герое белән Тукай арасында уртак һәм аермалы яклар. Кечкенә Габдулланың **Хаҗиморат Казаковның «Бәләкәй Апуш» картинасында** сурәтләнеше.

**Рабит Батулла.**

**«Тукай-Апуш» әсәре.** Кечкенә Апушка хас сыйфатлар. Аның иптәшләреннән аермалы ягы – сәләтле булуы.

**Габдулла Тукайның Кырлайдагы музее.** Музей урнашкан төбәк. Андагы истәлекле экспонатлар.

*Теоретик мәгълүмат. Мемориаль комплекс.*

**Ибраһим Газның «Илдус» әсәре.** Малайның үз-үзен тотышы. Лагерьда Илдус белән бәйле вакыйга турында сөйләшү.

**«Салават күпере» журналы**. Аның тарихы һәм бүгенгесе турында мәгълүмат.

**VI бүлек. Ватаным өчен.**

**Гадел Кутуйның «Рөстәм маҗаралары» повестеннан** «Әби экияте», «Яз җиткәч», «Сихерле чәчәкләр», «Расад» бүлекләрен уку. Рөстәм образы турында сөйләшү. Малайга хас сыйфатларны табу. Хыял белән чынбарлык арасындагы аерманы табарга өйрәнү.

**Муса Җәлил.**

**«Сагыну», «Соңгы җыр» шигырьләре**. Аларга салынган хисне аңлау. **«Алтынчәч»либреттосыннан** өзек өйрәнү. Либреттоның экияткә һәм дастанга нигезләнеп язылган булуы. Аның төп каһарманнары: Тугзак ана, Җик, Алтынчәч. **Нәҗип Җиһановның** либреттога музыка язуы. Композиторның иҗаты.

**Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры** турында мәгълүмат.

**Җырчы Мөнирә Булатова иҗаты.** Ул башкарган арияләр. Язмышының опера сәнгате белән бәйле булуы.

**Фатих Кәримнең «Кыр казы», «Ватаным өчен», «Сөйләр сүзләр бик күп алар...» шигырьләрен** уку. Аларда Туган илне саклау, ярату хисләренең салынган булуы.

**Лев Кассильнең «Мәңгелек хәтер».** Мәскәү Кремле янындагы мәңгелек ут.1965 нче елда Мәскәүгә герой-шәһәр исеме бирелүе.

**Фаил Шәфигуллин.**

**«Сугышчан бурыч» хикәясе.** Әсәрдә Нәбир исемле малайның үз-үзен тотышы. Малай кылган гамәлләр.

**Шәүкәт Галиев.**

**«Аталы-уллы солдатлар» балладасы.** Илне басып алучыларга көрәштә халыкның фидәкарьлеге. Ил батырларына хөрмәт.

*Әдәбият теориясе. Баллада.*

**VII. Кояшлы ил – бәхет иле.**

**Нәби Дәүлинең «Бәхет кайда була?» «Мин җирдә калам»шигырьләрендә** бәхет эзләү һәм табу кебек фәлсәфи мәсьәләнең чишелеше. Лирик герой өчен бәхетнең үзе яшәгән җирдә булуы.

*Теоретик төшенчә.Шигырь. Ритм. Рифма.*

**Мәдинә Маликованың «Оҗмах балалары».** Пьесада кешенең үз илендә, туганнары янында гына бәхетле була алуы.

**Фатих Хөсни.** Автор турында белешмә.

**«Чыбыркы» хикәясе** . Хикәядә малайның үз эшләре өчен җавап бирүе. Авторның бала психологиясен ачу үзенчәлеге.

*Әдәбият теориясе. Сюжет. Сюжет элементлары (экспозиция, төенләнеш, вакыйгалар үстерелеше, кульминация, чишелеш).*

**Фоат Садриевның «Көнбагыш чәчәге» хикәясе.** Яхшылыкның нәтиҗәсе яхшылык булуын аңлау.

**Әхмәт Рәшитов.**

**« Кояшлы ил – бәхет иле» шигыре.** Туган ил кадерен белергә өйрәтү. Лирик геройның кичерешләрен ачу.

**Мәгъсүм Хуҗин.**

**«Туган көн» хикәясе.** Олыларга игътибарлы булырга өйрәтү. Кешеләрнең күңелен күтәрү – зур бәхет булуын ачыклау.

**VIII. Кеше – табигать баласы.**

**Равил Фәйзуллинның «Табигать кочагында» шигыре.** Шигырьдә табигатьне саклау, аны ярату хисләре өстенлек итүен ачыклау.

**Мөдәррис Әгъләмовның «Матурлык минем белән» шигыре, «Җир-ана, кояш һәм башкалар» балладасы.** Матурлыкны табигатьтән эзләү мотивы. Табигатьнең кешеләргә мәрхәмәтле булуы, аны сакларга кирәклеге.

**Рәссам Иван Иванович Шишкин иҗаты.** Аның Татарстан белән бәйле язмышы. Иҗаты.

**Нури Арслановның «Ринат авылда» шигыре.** Лирик геройның авыл табигате, мохите белән танышуы.

**Гәбделхәй Сабитов.**

**«Чәчәк нигә боекты?» хикәясе.** Кызчыкның әнисенә ярдәм итүе, табигатьне яратуы.

**Борис Вайнерның «Искиткеч китап».** Елның дүрт фасылы. Аларның һәрберсе үзенчә матур булуы.

**IX. Эш беткәч көләргә ярый.**

**Ләбиб Леронның «Пирамида» хикәясе.** Укучыларда белем алуга теләк тудыру. Укымыйча гына белемле булып булмавын ачыклау.

*Теоретик төшенчә. Юмор.*

**Алмаз Гыймадиев.**

**«Зөлфия + ... мин» хикәясе.** Яшүсмерләрне беренче мәхәббәт хисләренең сурәтләнеше. Язуда гына түгел, тормышта да хаталар җибәрергә ярамавын ачыклау.

**Шәүкәт Галиев.**

**«Ул кем?» «Әлләкем», «Мәрзия мәсьәләсе» шигырьләре.** Шагыйрьнең табышмак, юмористик шигырьләрендә бала хисләренең ачылышы.

### Әсәрләр минимумы

Дәреслеккә салынган әдәби әсәрләрнең нигезен “Үрнәк программа”да күрсәтелгән (төзүчеләре: *Ф.Х.Җәүһәрова, К.С.Фәтхуллова)* әдәби әсәрләр минимумы (7 әсәр) тәшкил итә. Алар түбәндәгеләр:

К. Насыйри, “Патша белән карт”;

Г. Тукай, “Су анасы”;

М. Җәлил, “Алтынчәч” (либреттодан өзек);

Ф. Кәрим, “Кыр казы”;

Ф. Хөсни, “Чыбыркы” (хикәясеннән өзек);

М. Әгъләм, “Матурлык минем белән”;

Н. Дәүли, “Бәхет кайда була?”

### Ятлау өчен тәкъдим ителә торган әсәрләр:

Дәрдемәнд, “Кил, өйрән...”

Ф.Кәрим, “Сөйләр сүзләр бик күп алар...”
Р.Фәйзуллин, “Табигать кочагында”

**Дәрестән тыш (өстәмә) уку өчен тәкъдим ителгән әсәрләр**
(укытучы сайлавы буенча):

Башмак (татар халык әкияте)
Төлке белән Алёнушка (рус халык әкияте)
Карга ни өчен исемен әйтеп бетерми? (башкорт халык әкияте)
Куркак юлдаш (татар халык әкияте)
Каюм Насыйри. Күләгә
Фәнис Яруллин. Хәтерсез күке
Владимир Даль. Кар кызы
Ганс Христиан Андерсен. Борчак өстендәге принцесса
Рудольф Эрих Распе. Сигез аяклы куян
Тукай-Апуш. Рабит Батулладан
Илдус. Ибраһим Газидан
Мөнирә Булатова
Фатих Кәрим. Ватаным өчен
Мәңгелек хәтер. Лев Кассильдан
Сугышчан бурыч. Фаил Шәфигуллиннан
Шәүкәт Галиев
Оҗмах балалары. Мәдинә Маликовадан
Көнбагыш чәчәге. Фоат Садриевтан
Әхмәт Рәшитов. Кояшлы ил – бәхет иле
Туган көн. Мәгъсүм Хуҗиннан
Нури Арсланов. Ринат авылда
Чәчәк нигә боекты? Габделхәй Сабитовтан
Борис Вайнер. Искиткеч китап
Шәүкәт Галиев. Мәрзия мәсьәләсе

## Тематик планлаштыру

| № | Төп темалар | Уку-укыту эшчәнлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Акыллы сүзгә ни җитә! (Халык авыз иҗаты) | Халык авыз иҗаты турында белемнәрне тирәнәйтү, системалаштыру, халык авыз иҗаты һәм матур әдәбиятның уртак һәм аермалы якларын күрсәтү, рус халык авыз иҗаты белән чагыштыру | 1 |
| 2 | Белмәгәнгә - әкият, белгәнгә - чын (Әкиятләр) | Әкият турында булган белемнәрне тирәнәйтү, әңгәмәдә катнашу | 1 |
| 3 | Яхшылыкка каршы - яхшылык (“Ак бүре” әкияте) | “Акбүре” әкиятен уку, эчтәлеген ачыклау, тирәк сораулар буенча анализлау. Әкият геройларына бәя бирү, гомумиләштереп нәтиҗәләр чыгару | 3 |
| 4 | “Булма син төлке - булырсың көлке ” (“Абзар ясаучы Төлке” әкияте) | Эчтәлекне сорауларга җавап бирү барышында ачыклау, әкияттәге уңай һәм тискәре образларны табу, аларга хас сыйфатларны билгеләү | 1 |
| 5 | Ана дигән хәзинә (“Өч кыз” татар халык әкияте) | Текстны сәнгатьле уку, дәреслектә, эш дәфтәрендә биремнәр эшләп, әкиятнең эчтәлегенә төшенү, кызларга сыйфатнамә бирү | 1 |
| 6 | Борын-борын заманда... (кабатлау) | Халык әкиятләрен гомумиләштереп кабатлау, аларның төрләргә бүленешен искә төшерү | 1 |
| 7 | Яшәгән, ди, булган, ди... (К.Насыйри. “Патша белән карт” әкияте) | Язучы турында белемнәрне үзләштерү, әкиятне уку, текстка якын килеп эчтәлеген сөйләү; «автор әкияте», «әдәби герой» төшенчәләрен аңлату | 1 |
| 8 | Юк дип әйтмә, бардыр ул... (Г.Тукай. “Су анасы” әкият-поэмасы) | Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, әкиятне өйрәнү, әкият-поэмада әкияткә хас сыйфатларны табу; «шигъри әсәр», «әкият-поэма» төшенчәләрен аңлату | 1 |
| 9 | Әкиятче бездә кунакта (Т.Миңнуллинның “Гафият турында әкият” әсәре) | Әкият-пьесаны сәнгатьле итеп уку, рольләргә бүлеп уку, аңлаганны сораулар ярдәмендә тикшерү, анализлау | 1 |
| 10 | Әкияттә кунакта (“Әкият” курчак театры тексты) | Яңа материал белән танышу, укытучының кереш сүзе, укылган текст буенча фикер алышу | 1 |
| 11 | Әкият тә түгел, чын да түгел... (А.Тимергалин. “Сәер планетада” әсәре) | Хикәяне уку, сүзләрне аңлату, образларга телдән характеристика бирү, сораулар буенча төп фикерне табу, нәтиҗә чыгару | 3 |
| 12 | Белем - бәхет ачкычы ( “Белемгә омтылу” тексты) | Уку, эчтәлеге буенча фикер алышу, мәкальләр уку, рәсемнәр күзәтү. | 1 |
| 13 | Белем укудан башлана (“Мөхәммәдия” мәдрәсәсе” тексты) | Китаптагы текст белән танышу, уку, белем алу, татар халкының белемле булуы турында сөйләшү, укымышлылык турында фикер алышу, укытучы тәкъдим иткән истәлекләр белән танышу | 1 |
| 14 | Укытучылар мәктәбе (“Казанның Татар укытучылар мәктәбе” тексты) | Текстны уку, тема буенча укытучының кереш сүзен тыңлау, әңгәмәдә катнашу | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 15 | Казан университеты (“Казан университеты” тексты) | Текст җөмләләрен кыскартып әйтү, сорауларга җавап бирү, әңгәмәдә катнашу, төрле биремнәр эшләү | 1 |
| 16 | Галим кеше хөрмәткә лаек! (Г.Исхакый. “Мөгаллим” ) | Әсәрне уку, эчтәлеген аңлау, фикер алышу, идеясен билгеләү | 1 |
| 17 | Кил, өйрән... (Дәрдемәнд. “Кил, өйрән...” шигыре) | Мәктәптә өйрәтелә торган телләр турында фикер алышу, сорауларга җавап бирү, идеяне билгеләү | 1 |
| 18 | Укысаң - белерсең (кабатлау) | Әңгәмәдә катнашу, нәтиҗәләр чыгару, белемнәрне тикшерү максатыннан тест эшләү | 1 |
| 19 | Исемдә калганнар (Г.Тукай.“Исемдә калганнар”) | Текстны уку, тәрҗемә итү, укылган өлеш буенча фикер алышу, сөйләү, образларга бәяләмә бирү, сүзлек эше, биремнәр эшләү | 4 |
| 20 | Музейларда - хәтер («Габдулла Тукайның Кырлайдагы музее» тексты) | Тукай музее белән танышу. Видео, презентацияләр карау | 1 |
| 21 | Ямьле балачак (Кабатлау) | Укыганнарны искә төшереп, гомумиләштереп кабатлау. Тексттан мисаллар китереп, теорияне искә төшерү. Белемнәрне тикшерү максаты белән тест эшләү | 1 |
| 22 | «Әгәр мин тылсымчы булсам...» (Г.Кутуй. «Рөстәм маҗаралары») | Фантастик хикәяләүне аңлап, әсәрне аңлау, сугыш чоры, партизаннар турында әңгәмә кору, сүзләрне тәрҗемә итеп, мәгънәләрен аңлату, геройга характеристика бирү, нәтиҗә чыгару | 4 |
| 23 | Мин сине шундый сагындым... (М.Җәлил. «Сагыну» шигыре) | Язучы иҗаты белән танышу, шагыйрьнең патриотик хистә язылган шигырьләрен искә төшерү, әсәрне укып, укытучы җитәкчелегендә бергәләп анализлау, нәтиҗә ясау | 1 |
| 24 | Гомере аның моңлы бер җыр иде... (М.Җәлил. «Соңгы җыр» шигыре) | Шигырьне уку, сорау-биремнәргә җавап эзләү, шигырьне анализлау | 1 |
| 25 | М.Җәлилнең «Алтынчәч» либреттосы | Презентация карау, шигырьне уку, эчтәлек белән танышу, әсәрнең төп фикерен аңлату, эш дәфтәрендә биремнәр эшләү | 2 |
| 26 | Опера ничек туа? (Н.Җиһанов, «Алтынчәч» операсы турында») | Текстларны уку, сөйләү, тексттан мисаллар табып уку, төп фикерне аерып чыгару, сорауларга җавап эзләү | 1 |
| 27 | Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры | Текст белән танышу, текстның төп фикерен аңлату, эш дәфтәрендә биремнәр эшләү, диалогта катнашу | 1 |
| 28 | Кыр казы (Ф.Кәримнең «Кыр казы» шигыре) | Сәнгатьле уку, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр аша лирик әсәрне анализлау | 1 |
| 29 | Сөйләр сүзләр бик күп алар... (Ф.Кәримнең «Сөйләр сүзләр бик күп алар» шигыре | Сәнгатьле уку өстендә эшләү, әңгәмә, сорауларга җавап бирү | 1 |
| 30 | Аталы-уллы солдатлар (Ш.Галиев. «Аталы-уллы солдатлар» балладасы) | Уку, рәсемнәр буенча әсәрнең эчтәлеген сөйләү, сорауларга җавап бирү, фикерне ачу | 1 |
| 31 | Сугыш кайтавазы (Кабатлау) | Укыганнарны гомумиләштереп кабатлау, тынычлык өчен көрәш алып баручылар турында фикер алышу, нәтиҗәләр чыгару, белемнәрне тикшерү максаты белән тест эшләү | 1 |
| 32 | Бәхет кайда була? (Нәби Дәүлинең «Бәхет кайда була?» шигыре) | Язучы иҗатына күзәтү ясау, әсәрен укып, ярдәмче сорауларга нигезләнеп, аңа бәя бирү, мәкальләр белән танышу | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 33 | Туган җирдә минем бәхетем (Нәби Дәүлинең «Мин җирдә калам» шигыре) | Шигырьне сәнгатьле уку, мәгънәсенә төшенү максаты белән сорауларга җавап бирү, әсәр буенча фикер алышу | 1 |
| 34 | Минем холкым - минем язмышым (Фатих Хөснинең «Чыбыркы» әсәре) | Укытучының сөйләвен тыңлау, әсәрне өлешләргә бүлү, проблемалы сорау кую, анын хәл итү, анализлау, нәтиҗә ясау | 4 |
| 35 | Кояшлы ил — бәхет иле (Кабатлау) | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, нәтиҗәләр чыгару, анализ ясау, җыр өйрәнү, белемнәрне тикшерү максатыннан тест эшләү | 1 |
| 36 | Табигать кочагында (Р.Фәйзуллинның «Табигать кочагында» шигыре) | Уку, әңгәмә, биремнәрне үтәү, таблица тутыру, рәсем ясау, шигырьне ятлау | 1 |
| 37 | Матурлык минем белән (М.Әгъләмнең «Матурлык минем белән» шигыре) | Уку, сорауларга җавап бирү, сюжет төшенчәсен искә төшерү. Шигырь буенча фикер алышу | 1 |
